ҖОМГА
12 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 85 (5885)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы бүлеге 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

Скандинавиядәге соңгы вакыйгаларга карата

Скандинавиядәге вакыйгалар җәелеп баралар. Англия һәм Франция, Германиянең сугыш позицияләрен өзү теләге белән, Скандинавия илләренең нейтраль суларына барып кергәннән соң һәм Германия тарафыннан моңа каршы күрелгән чаралардан соң Дания һәм Норвегия тегеләй дә, болай да Германиягә кушылырга кирәклек алдына килеп бастылар. Германия гаскәрләре Данияне, Дания белән Швеция арасындагы бугазларны, Норвегиянең төп портларын алдылар. Вакыйгалар әле логик нәтиҗәгә килеп җитмәгәннәр,—моның өчен вакыт кирәк,—ләкин Европада килеп чыккан яңа хәлдән хәзер үк инде кайбер бәхәссез нәтиҗәләрне ясарга мөмкин.

Барыннан да элек, хәзерге хәлдә Германиянең хәрәкәтләре мәҗбүри хәрәкәтләр булды дигән нәтиҗәгә килергә кирәк. Һич шиксез, Германия гаскәрләренең Даниядәге һәм Норвегиядәге хәрәкәтләре Англиянең һәм Франциянең аннан элек булган хәрәкәтләре аркасында килеп чыктылар. Аларның бу хәрәкәтләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт булды: Скандинавия илләренең нейтралитетын һәм, димәк, суверенитетын да бозу, Норвегиянең нейтраль суларына миналар кую, Скандинавия илләреннән Германиягә руда һәм авыл хуҗалыгы продуктлары чыгаруны тыю, сугыш хәрәкәтләрен Скандинавиягә күчерү политикасы,—димәк, Германия гаскәрләренең тылына керү политикасы. Англия һәм Франция Германиянең сугыш позицияләрен өзәргә, һәм үзләренең позицияләрен сизелерлек төстә яхшыртырга теләделәр. Германия, начар хәлгә төшәргә теләмәгәнлектән, моңа каршы үзенең чараларын күрергә мәҗбүр булды.

Аннан соң, һич шик юк, Германия Даниядә һәм Норвегиядә үзенең хәлен ныгытып, үзенең хәрби-стратегик һәм хуҗалык позицияләрен сизелерлек дәрәҗәдә яхшыртты һәм бара торган сугышта Англиянең һәм Франциянең позицияләрен шулай ук сизелерлек дәрәҗәдә өзде. Нарвикның, Тронгеймның, Бергенның, Ютландиянең һәм Швеция белән Дания арасындагы бугазларның Германия кулына күчүе Төньяк диңгездәге хәлне тамырыннан үзгәртте. Германиянең кораллы көчләре Англиянең хәрби диңгез базаларына һәм промышленность районнарына турыдан-туры якынлаштылар. Германиянең авиация көчләре көтелмәгән яңа мөмкинлекләр алдылар. Төньяк Шотландия суларында Англиянең хәрби диңгез флотының тыныч торуына чик куелды. Германия континентта үз гаскәрләренең тылын Англия—Франция ударыннан тәэмин итте.

Шулай ук хуҗалык ягыннан да Англия позицияләренең зарары хисабына Германиянең позицияләре сизелерлек яхшырды. Моннан элек Скандинавия агачы, Скандинавиянең азык продуктлары, шулай ук тимер рудасы Англиягә чыгарыла иде. Хәзер инде алар Германиягә чыгарылачак. Шулай ук Швециянең дә Германия тәэсире астында калганлыгын инде әйтеп тә тормыйбыз. Хәзер Швециянең Төньяк диңгезгә һәм Атлантик океанга чыгу юлы Германия кулында һәм хәзер инде Швеция Германия интереслары белән хисаплашмый кала алмый.

Кайберәүләр, Германия үзенең Скандинавиядәге хәрәкәтләре белән халыкара хокук принципларын бозды, диләр, ул Дания белән һөҗүм итешмәү турындагы договорны кәгаз кисәгенә әйләндереп калдырды, диләр һ. б. Ләкин хәзер инде, Англия һәм Франция Скандинавия илләренең суверенитетын бозып, Германиянең интересларына зиан китереп, шуның белән моңа каршы Германия чараларын китереп чыгарганнан соң Германиянең Скандинавиядәге хәрәкәтләренең хокуклымы яки хокуксызмы икәнлеге турында арзанлы зарланулар белдерү,—үзеңне көлке хәлгә кую дигән сүз. Сугышның үз логикасы бар, ул башка һәр төрле логикадан көчлерәк. Әгәр дә сугышучы бер як сугышучы икенче якны бууны теләк итеп куя торган чаралар күрә икән, ул вакытта бу соңгысы, әгәр дә үз-үзен үтерергә теләмәсә, кулын баглап утыра алмый.

Шулай ук сугышучы бөек державаларның хәрәкәтләренә якын урында һәм шул хәрәкәтләр юлында урнашкан кечкенә илләрнең „абсолют нейтралитеты“ турындагы нәтиҗә дә килеп чыга. Тәҗрибә күрсәткәнчә, „абсолют нейтралитет“, әгәр дә аны якларлык реаль көч булмаса, ул фантазия. Ә кечкенә илләрнең нак әнә шул көчләре җитешми. Бөек державалар үзара үлем сугышы алып барганда, кечкенә илләрнең, нейтралитет флагы артына яшренеп, бу сугыштан баюлары чиксез дәвам итә ала дип уйлау акылсызлык булыр иде. Әйтергә кирәк, сугыш нейтраль һәм бәйсез булып калырга теләүче кечкенә илләрнең ышанычларын киметә, аларны иң аз минимумга калдыра. Менә шуңа күрә дә кайбер кечкенә нейтраль илләрнең, сугышның килеп чыгуына һәм көчәюенә ярдәм итә торган политикаларын үз-үзеңне үтерү политикасы дип әйтмичә, башкача әйтеп булмый.

Шулай ук Англиянең һәм Франциянең Финляндиягә „ярдәме“ турындагы нәтиҗә дә кызыклы. Бу нәтиҗәне Скандинавиядәге соңгы вакыйгаларның барышы күрсәтә. Хәзер инде моның нинди „ярдәм“ булганлыгы һәм аның нәрсә өчен билгеләнгәнлеге ачык. Чемберлен үзенең СССР га каршы Финляндиягә ярдәмгә хәзер торган „экспедиция корпусы“ барлыгына ышандырды. Даладье дә үз чиратында, СССР га каршы Финляндиягә ярдәмгә үз „корпусы“ барлыгына ышандырды. Бу джентльменнәрнең тик бер генә нәрсәләре—бу „корпуслар“ ны Норвегия һәм Швеция аркылы үткәрү хокуклары гына булмады. Һич шиксез, әгәр дә бу атаклы „корпуслар“ ның бурычы Финляндиягә кадәр барып җитү булган булса иде,—ә моңа шикләнергә бик мөмкин,—чынлыкта алар бары тик 2—3 айдан соң гына, ягни Финляндия ак гвардеецлары инде Совет гаскәрләре тарафыннан тәмам тар-мар ителгәннән соң гына Финляндиягә барып җиткән булырлар иде. Димәк, бу „корпуслар“ котылгысыз рәвештә Норвегиядә һәм Швециядә калырга тиеш булырлар иде. Нәрсә өчен? Швециянең һәм Норвегиянең кайбер әһәмиятле стратегик пунктларын басып алу, бу илләрне сугышка тарту һәм Германиягә каршы яңа фронт төзү өчен. Димәк, Англия һәм Франция большевикларга каршы көрәш сылтавы астында, СССР га каршы көрәш һәм Финляндияне „яклау“ лозунгысы астында Германиягә каршы сугышны киңәйтү өчен Скандинавиядә ныгып калырга теләгәннәр. Совет—Финляндия солых договоры төзелү бу махинацияне өзде, Англияне һәм Францияне үзләренең Финляндияне „яклау“ битлеген, „бөтен дөнья большевизмына“ каршы көрәш битлеген алып ташларга мәҗбүр итте. Үзләре өчен уңайлы битлекләре калмаганнан соң алар турыдан-туры һәм ачыктан-ачык Норвегиянең нейтраль суларын Англиянең һәм Франциянең кораллы көчләре белән басып алу турындагы, Скандинавиядән Германиягә товар чыгаруны туктату турындагы һәм, димәк, Скандинавияне сугышка тарту турындагы мәсьәләне куярга мәҗбүр булдылар. Бу юлы инде Финляндиягә „ярдәм“ турында сүз булмады, чөнки бу „ярдәм“ бары тик битлек өчен генә кирәк иде, шул битлек белән капланырга мөмкинлек булган вакытта гына кирәк иде. Хәзер инде сүз Германиягә каршы сугышны турыдан-туры һәм битлексез генә киңәйтү турында барды, чөнки Советлар Союзы кулы аларның бу битлекләрен алып ташлады.

Хәзер бу бәхәссез.

(„Известия“ нең 11 нче апрельдәге баш мәкаләсе).

15 нче апрель, кич 6 сәгатьтә Менжинский исемендәге клубта (Карл Маркс урамы, 25) хезмәт ияләре депутатлары

КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫНЫҢ 2 нче СЕССИЯСЕ ЧАКЫРЫЛА

Хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитеты.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮНЕ БОЛЬШЕВИСТИК ХӘЗЕРЛЕК БЕЛӘН КАРШЫЛЫЙК

Югары иген уңышы өчен

Кама Тамагы районы, Чаллы авылының „Авангард“ колхозы (председателе иптәш Мифтахов) язгы чәчүгә яхшы хәзерлек белән килә. Колхоз барлык чәчү мәйданына җитәрлек орлык белән тулысынча тәэмин ителгән. Орлыкларның сыйфаты яхшы. Агротехник иптәш Миңнахҗев колхозлар турында аеруча кайгыртучанлык күрсәтә. Ул чәчүлекләрнең торышын системалы рәвештә тикшереп бара. Орлыкларны яровизацияләү һәм агулау өчен барлык кирәкле әйберләр хәзерләнгән. Бәрәңге яровойлаштыруга күптән салынган.

„Авангард“ колхозы шул ук районның Бортас авылындагы „Безнең Теләк“ колхозы белән ярыша. Шушы көннәрдә ярыш договорының үтәлеше тикшерелде. „Безнең Теләк“ колхозыннан килгән тикшерү бригадасы „Авангард“ ның язгы чәчүгә хәзерлеген яхшы дип тапты. Социалистик ярыш договорының үтәлешен тикшерү һәр ике колхозда да язгы чәчүгә хәзерләнүдә күп кенә кимчелекләрне бетерүгә ярдәм итте.

„Авангард“ колхозының кайбер бригадалары, мәсәлән, беренче бригада (бригадиры иптәш Хәйруллин) кар тоту һәм җирле ашлама хәзерләү планнарын арттырып үтәгән, басуга 604 йөк тирес чыгарган һәм 22 гектар мәйданда кар суы тоту үткәргән.

„Авангард“ колхозында массакүләм аңлату эшләре куелган да канәгатьләнерлек. Һәм һәрбер бригадада стена газеталары системалы рәвештә чыгарыла. Газеталар язгы чәчүгә хәзерлек һәм югары уңыш яклары һәм шул ук кимчелекләрне тикшерәләр.

К. Гайнанов.

Колхозларда орлык белән үзара ярдәмләшү

Чистай районының „Индустрия“ колхозы „Борьба за урожай“ колхозына бөртекле 150 центнер орлык һәм борчак орлыгы, „Победа“ колхозы „Активист“ һәм Ворошилов исемендәге колхозына 106 центнер, „Заветы Ильича №1“ колхозы „Смена“ колхозына 53 центнер бодай бирделәр.

Ширәмәт районының „Сухарево“ колхозы үзара ярдәмләшү тәртибендә „Память Ленина“ колхозына 120 центнер чәчүлек орлык бирде. Ленин исемендәге колхозның алдынгы колхозчылары инициативасы белән колхозга колхозчыларның индивидуаль рәвештә орлык белән ярдәм итүләре киң җәелде. Техник культуралар орлыкларын алмаштыру өчен 150 пот орлык җыелды.

Әлмәт районының „Мораг“ колхозында чәчүлек орлыкларның сыйфаты начар иде. Колхозчылар гомуми җыелышта үз колхозларына чәчүлек орлык белән ярдәм итәргә карар чыгардылар. Шул ук җыелышта 50 колхозчы колхозга 350 пот чәчүлек орлык бирергә теләкләрен белдерделәр. Уксанова, Гатина, Мөхәмәдиева, Мостафин, Хәнипов иптәшләр һ. б. бөерсә 12 пот орлык бирделәр. (ТатТАСС).

МӘСЛИМ. (Телефон буенча). Колхозлар бөртекле культура орлыклары белән тулысынча тәэмин ителделәр.

Бәрәңгене колхозара ярдәм тәртибендә таба чаралары күрелә. „Роща“ колхозы „Новая жизнь“ колхозына 25 центнер бәрәңге бирде инде.

Район колхозларында авыл хуҗалыгы машиналарын һәм тагылма коралларга ремонт тәгәлләнде. Ләкин кайбер колхозларда ат җигүләре, арбалар җитәрлек түгел.

Мөслим МТС ында тракторларга ремонт тәгәлләнде. Тракторчы кадрлар җитәрлек бар.

Районда бәрәңге яровойлаштыру башланды. Орлык агулау материаллары да җитәрлек хәзерләнде.

Мөхәттинов.
Район җир бүлеге мөдире.

СОЦИАЛИСТИК ЯРЫШ ДОГОВОРЫН ТИКШЕРДЕЛӘР

Әтнә районының Киров исемендәге колхоз делегациясе „Тугай № 1“ колхозында социалистик ярыш договорының үтәлешен тикшерде. Делегация бу колхозда язгы чәчүгә хәзерлекне начар дип тапты.

Басуга тирес чыгару планы бары 29 процент, көл җыйнау 17 процент, кош тизәге җыйнау планы 27 процент кына үтәлгән.

Торф хәзерләү планы бөтенләй үтәлмәгән.

Колхозчылар арасында массакүләм аңлату эшләре алып бару һич тә канәгатьләнерлек түгел. Колхозда учет эшләре дә дөрес куелмаган, буталган.

Делегация колхоздагы җитешсезлекләрне бетерү турында конкрет тәкъдимнәр бирде.

М. Шагеев.



Юдино районының Буденный исемендәге колхоз бригадиры Урусев (сулда), колхоз председателе Чкапов, Борисоглебский авыл советы председателе Тарасов иптәшләр авыл хуҗалыгы инвентарьларын тикшерәләр. В. Лужбин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Кыр эшләре башланды

Чаллы районы колхозларында кыр эшләре башланды. „Нива“ колхозында өлгергән участкыларда язгы сөрү һәм туңга сөрелгән җирләрне тырмалау бара. Шулай ук бу эшкә „Красная Шильна“ колхозында да керештеләр. Максим Горький, Крупская һәм Наумовлар исемендәге колхозлар, „Якты Гардәле“, „Кызыл Көч“ һәм башка берничә колхозда 11 нче апрельдә кыр эшләрен башладылар.

***

Кукмара районының „Завет Ильича“ колхозы 9 нчы апрельдә район күләмендә беренче булып 10 гектар мәйданда клевер чәчте. (ТатТАСС).

Тракторчылар йөкләмәсе

Беренче Май МТС ы тракторчыларының һәм трактор бригадалары бригадирларының җыелышы үткәрелде. Җыелышта Беренче Май районы белән Шөгер районы арасында һәм Беренче Май МТС ы белән Чишмә МТС ы арасында төзелгән ярыш договорларының үтәлешен тикшерүнең нәтиҗәләре каралды.

Җыелышта катнашучы тракторчылар һәм трактор бригадалары бригадирлары үз өсләренә конкрет йөкләмәләр алдылар.

Трактор бригадасы бригадирларыннан Әсәдуллин һәм Гумеров иптәшләр үз бригадаларында һәрбер ЧТЗ тракторы белән 2.200 гектар, СТЗ тракторы белән 1.000 гектар эшләргә йөкләмә алдылар. Тракторчылардан Шәрәфеттинов, Гыйрфанов иптәшләр СТЗ тракторында үз сменаларында 650 шәр гектар эшләргә йөкләмә алып, үзара социалистик ярыш договоры төзеделәр.

Я. Шәрипов.

Зур кызыксыну белән

ДӨБЪЯЗ, 11 апрель. (**Телефон буенча**). „Авыл хуҗалыгы продуктларын хәзерләү һәм сатып алу политикасын үзгәртү турында“ ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарын Дөбъяз районы колхозларында гаять зур кызыксыну белән өйрәнәләр.

„Яңа юл“ колхозы членнары карарны өйрәнү өчен 10 нчы апрельдә махсус рәвештә гомуми җыелыш җыйдылар. Җыелышта карарның әһәмияте турында бик күп иптәшләр чыгып сөйләделәр.

Х. Касыймов.

„Татарстан“ колхозы чәчүгә хәзер түгел

Норлат районының „Татарстан“ колхозы язгы чәчүгә бик начар хәзерләнгән. Колхозда ремонттан чыккан чәчү машиналары, сабаннар һәм тырмалар төрлесе-төрле җирдә пычракта чәчелеп яталар. Ә транспорт әйберләренә хәтта ремонт та ясалмаган һәм моның өчен кирәкле материаллар да хәзерләнмәгән.

Орлык агулау һәм яровойлаштыру өчен хәзерлек юк.

Язгы чәчү һәм аның әһәмияте турында колхозчылар арасында бернинди аңлату эшләре алып барылмый. Кыр эшләрендә катнашырга тиешле колхозчылар язгы чәчүдә нинди эштә һәм кайда эшләячәкләрен белмиләр.

К. Сафин.

Рейднең башлангыч йомгаклары һәм хәбәрчеләр алдындагы бурычлар

Татарстан МТС ларында, колхозларында һәм совхозларында язгы чәчүгә хәзерлекне тикшерү буенча эшче-авыл хәбәрчеләренең рейде тәмам булды. Рейд 1 нче апрельдән 10 нчы апрельгә кадәр дәвам итте.

Башлангыч йомгаклар рейднең күп кенә районнарда уңышлы, массовый күләмдә үтүен күрсәтәләр. Рейд алдына куелган төп бурычлар—чәчүгә хәзерлектәге кимчелекләрне ачу, аларны рейд барышында ук бетерү чараларын күрү һәм алдынгыларның уңышларын уртаклашу бурычлары нигездә уңышлы үтәлделәр.

Эшче-авыл хәбәрчеләренең рейде массовый күләмдә үтүне күрү өчен кайбер саннарны алып карыйк.

Мамадыш районының 69 колхозында һәм 3 совхозында рейд буенча 49 бригада эшләде. Ул бригадаларга хәбәрчеләрдән—90 кеше, район активыннан 57 кеше һәм колхоз активыннан 138 кеше катнашты. Тәкәнеш районында 46 бригадада 150 хәбәрче һәм 46 активист эшләде.

Рейд буенча Дөбъяз районы колхозларында 71 бригаданың һәрберсенә дип әйтерлек хәбәрчеләр җитәкчелек итте. Рейдкә Актаныш районында—87 хәбәрче, Норлат районында—50, Минзәләдә—40, Ютазыда—66 хәбәрче катнашты һәм башкалар.

Язгы чәчүгә хәзерлекне тикшерү кебек аеруча әһәмиятле эшкә хәбәрчеләрне һәм гомумән район һәм авыл активын тарту, партиянең район комитетларының һәм район газеталары редакцияләренең бу эшкә зур әһәмият биргәнлекләрен күрсәтә. Һәм шулай эшләгән районнарда хәбәрчеләр рейде чәчүгә хәзерлекне тикшерү эшенә бик зур ярдәм итте. Бу 10 көндә колхозлар нигездә чәчүгә хәзерлекне тикшерү белән шөгыльләнделәр, кимчелекләрне бетерү өчен чаралар күрделәр, колхозчыларның игтибарын чәчүгә хәзерлеккә тупладылар, күп колхозларда рейд барышында стена газеталары чыгару эше юлга салынды.

Рейд нәтиҗәләре, кагыйдә буларак, һәрбер колхозда дип әйтерлек, правление утырышларында тикшерелеп, кимчелекләрне бетерү өчен ашыгыч чаралар күрелде. Мәсәлән, Шөгер районының „Дружба“ колхозында рейд нәтиҗәләрен правлениедә тикшергәннән соң орлыкларны чистарту эше сменалап оештырыла, яровойлаштыру өчен урын табу чаралары күрелә, бригадалар, звенолар арасында социалистик ярыш договорлары төзелә. Шул ук районның „Яңа юл“ колхозында рейд бригадасының тәкъдимнәре буенча 4 нче һәм 6 нчы бригадаларда звенолар төзелә, аларга участкылар беркетелә.

Рейдкә катнашучылар Апас районында да зур эш алып бардылар. Район газетасы „Бригадир“ рейд барышын яхшы, киң итеп яктырта. Радио аша махсус чыгышлар үткәрде, аңлатмалар бирде, тәҗрибәләрне уртаклашты.

Дөбъяз районының „Чорнаш“ колхозында хәбәрче иптәш Гәрәев җитәкчелегендәге бригада колхозга яшелчә орлыклары табуда ярдәм итте. „Кызыл байрак“ колхозында рейд бригадасы члены иптәш Хәбибуллина атларны группаларга бүлүдә, ат караучылар арасында социалистик ярыш оештыру буенча зур эшләр башкара.

Рейд барышында колхозларга чәчүгә хәзерлек буенча практик ярдәм күрсәтү фактлары гаять күп. Аларның барсы да рейд бригадалары составында башлыча эшлекле, колхоз тормышын якыннан белгән кешеләр булуны күрсәтәләр.

Ләкин хәзер, колхозларның чәчүгә хәзерлекләрен тикшерү эше тәмам булды, шуның белән өстебезгә төшкән бурыч үтәлде, дип хәбәрчеләр һич тә тынычланырга тиеш түгелләр. Хәзер хәбәрчеләр язгы эшләрнең икенче этапы һәм иң җаваплы этапы алдында торалар. Республиканың көньяк районнарындагы колхозлар кыр эшләренә керештеләр. Эш турыдан-туры язгы чәчүнең үзенә терәлеп калды. Шунлыктан, совет җәмагатьчелеге, партиянең масса белән бәйләнештә иң үткен коралы булып саналган матбугат вәкилләре—хәбәрчеләр язгы чәчү эшләренең башлануын һәм барышын яктырту эшенә җиң сызганып керешергә тиешләр.

Кыр эшләре башлану белән авыл хәбәрчеләренә басуларда булырга, чәчүнең кыска срокта һәм югары сыйфатлы булып үткәрелүенә эшлекле ярдәм итәргә кирәк. Хәбәрченең сүзе авторитетлы, хәбәрченең каләме үткен, алган фактлары дөрес, кимчелекләрне тиз бетерергә ярдәм итә торган булырга тиеш. Димәк, чәчү барышын тулы һәм дөрес итеп яктырту өчен басудан йомыш белән авылга кайткан кешеләр белән аяк өсли сөйләшү генә, бригадир кулындагы сводкага карап кына хөкем итү җитми; аның белән генә чынбарлыкны ачып булмый. Хәбәрчегә эш кайнаган җирдә: тракторчылар, чәчүчеләр, тырмачылар, сыйфат инспекторлары, орлык һәм ягулык ташучылар, звено башлыклары янында булырга, шулар белән бергә кайнарга кирәк. Хәбәрчеләр эштә үзләре үрнәк күрсәтергә, социалистик кырларның стахановчылары булырга, кыр станнарындагы, культвагоннардагы стена газеталарының җитәкчеләре булырга, агитаторлык эшләрен башкарырга тиешләр.

Аерым тракторчының, трактор отрядының, звеноларның уңышлы үрнәкләрен шул көнне үк барлык колхозчыларга җиткерергә кирәк. Бу эштә хәбәрчеләр, стена газеталары, бюллетеннәр, район газеталары бик зур урын тота алалар һәм тотарга тиешләр. Хәбәрче тормыштан, чәчүдән артта калмыйча, бәлки аның башында барса гына үз бурычын үти ала. Хәбәрчедә көндәлек тормыштагы һәрбер яңалыкны шунда ук эләктереп алу тойгысы булырга тиеш. Аның эше, аның язган хезмәте тик шул вакытта гына кыйммәтле һәм файдалы булачак.

Хәзер авыл хәбәрчеләре алдында торган бурычлар әнә шулар. Партия оешмалары, район газеталарының редакцияләре бу почетлы һәм мактаулы бурычны үтәүдә хәбәрчеләргә якыннан торып җитәкчелек итәргә, аларны чәчү эшләрен уңышлы үткәрү тирәсенә тупларга тиешләр.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

Марксизм-ленинизм теориясен өзлексез өйрәнергә

Партия пропагандасы эшен үзгәртеп кору буенча кинопленка фабрикасындагы партия оешмасы шактый уңышлы эшләр башкарды. Хәзер инде күп кенә иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н урта звено буенча өйрәнүне тәмамладылар. Алар хәзер марксизм-ленинизм классиклары әсәрләрен өйрәнәләр. 10 нчы производствоның өлкән инженеры Толстов һәм 8 нче производствоның техник конторасы начальнигы Мужиев иптәшләр марксизм-ленинизмны өйрәнүдә күпләргә үрнәк булырлык итеп эшлиләр. Алар хәзер икесе дә ВКП(б) ның Ленин райкомы лекторлары. Цех начальнигы Белый, юрисконсульт Фадеев һәм техник бүлекнең өлкән инженеры Мәҗитев иптәшләр үзләренең политик һәм теоретик белемнәрен күтәрү өстендә җидди рәвештә һәм тырышып эшлиләр. Оешмадан 8 иптәш кичке марксизм-ленинизм университетында укыйлар.

Партбюро членнары ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләр белән системалы рәвештә индивидуаль һәм групповой беседалар уздыралар. Бу беседалар китап өстендә үзлегеннән эшләүче иптәшләргә зур ярдәм итәләр. Мәсәлән, ВКП(б) члены иптәш Хөсәенев, аның белән беренче беседа ясаганда әле „Кыскача курс"ның икенче бүлеген генә өйрәнә иде. Бу беседа аңа зур йогынты ясады. Ул партия тарихын җидди рәвештә һәм тырышып өйрәнә башлады. Хәзер инде иптәш Хөсәенев „Кыскача курс"ның сигезенче бүлеген өйрәнә.

Соңгы вакытта партбюро членнары Толстов һәм Мужиев иптәшләр 10 нчы һәм 8 нче производстволарда эшләүче коммунистлар һәм партиясезләр белән теоретик беседалар уздырдылар. Кайбер иптәшләргә, аеруча яш коммунистларга алар күбрәк игътибар итәләр. Мәсәлән, яш коммунист иптәш Коков үзенең политик белемен күтәрү өстендә эшләми иде. Ул бер ел буена „Кыскача курс"ның беренче бүлеген генә укыган. Иптәш Мужиев аның белән ешрак сөйләште һәм бик күп мәсьәләләрдә аңа булышты. Хәзер иптәш Коков үзлегеннән укырга өйрәнде һәм „Кыскача курс"ның дүртенче бүлеген өйрәнү өстендә эшли.

Фабрикадагы партиясез интеллигенция арасында үзләренең идея-политик дәрәҗәләрен күтәрү буенча китап өстендә тырышып эшләүче иптәшләр бик күп. Мәсәлән, 10 нчы производствода эшләүче яш белгечләрдән Смолко, Прокофьева, Лушников һәм Катина иптәшләр „Кыскача курс"ның 12 бүлеген дә өйрәнеп конспект төзеделәр. Хәзер алар марксизм-ленинизм классикларының аерым әсәрләрен өйрәнәләр.

10 нчы производстводагы партия һәм комсомол группасы соңгы ике ай эчендә партия тарихын үзлекләреннән өйрәнүчеләр белән 8 тапкыр иптәшләрчә беседалар уздырды. Бу беседаларга алдан җидди хәзерлек алып барыла. Һәрбер иптәш алынган тема буенча нык лап хәзерләнә. ВКП(б) тарихын һәм өстәмә материаллар укый. Шуңар күрә дә монда уздырылган беседалар бик эшлекле үтәләр, беседага катнашучыларның һәрберсе алынган тема буенча үзенең аңлаганнарын чыгып сөйләргә ашыга. Бу производствода уздырыла торган беседаларга комсорг Богданова һәм райкомның штаттан тыш пропагандисты Лушников иптәшләр алдан ныклап хәзерләнәләр. Беседаларга, һәр хәлдә, партбюро членнарыннан берсе җитәкчелек итә.

Шул ук вакытта, партия пропагандасын оештыру һәм аңа җитәкчелек итү буенча партоешманың зур гына кимчелекләре дә бар. Безнең әле, барлык җитәкче работникларның да үзләренең теоретик белемнәрен күтәрү, партия тарихын өйрәнү өстендә системалы рәвештә эш алып баруларына ирешә алганыбыз юк. Үз өстендә эшләмәүчеләргә карата вактында тиешле чаралар күрмибез. Ә безнең партоешмада андый кешеләр бар. Мәсәлән, иптәш Муравкин партия тарихын үзлегеннән дә өйрәнми, түгәрәккә дә йөрми. Фабриканың оборудованиеләр бүлеге начальнигы, ВКП(б) кандидаты иптәш Дуденко әлегә кадәр „Кыскача курс"ның икенче бүлеген „өйрәнә". Ә лекцияләргә бөтенләй йөрми. Үзенең политик һәм теоретик белемен күтәрүгә игътибарсыз каравы турында иптәш Дуденкога берничә тапкыр күрсәтү дә булды инде. Ләкин ул күрсәтүләрне һәм тәнкыйтьне игътибарга алмый. Бөтен гаепне „вакыт юк" ка сылтарга маташа. Фабком председателе, ВКП(б) члены иптәш Кострев белән дә шундый ук хәл.

Партия уставы таләпләрен үтәмәүчеләргә карата, ягни үзенең теоретик белем дәрәҗәсен күтәрү өстендә эшләмәүчеләргә карата оешмада җәмагать фикерен тупламау—партия пропагандасының куелышындагы иң зур кимчелекләрнең берсе. Моның өчен, ВКП(б) Үзәк Комитетының 1939 нчы ел, 16 нчы август карарыннан соң, аерым коммунистларның партия тарихын ничек өйрәнүләре турындагы мәсьәләне гомуми җыелышта бары бер генә тапкыр тикшерелгәнлекне күрсәтү дә җитә.

Кинопленка фабрикасындагы партоешма бу кимчелекләрне кичекмәстән төзәтергә тиеш. Без, оешмадагы барлык коммунистларның партия тарихын өйрәнүләрен оештырырга, һәрбер коммунистның большевизм теориясен үзләштерү өстендә системалы рәвештә эшләвенә ирешергә тиешбез.

Г. Дорофеев.

Кинопленка фабрикасының партбюро секретаре.



ВКП(б) ның Юдино район комитеты башлангыч партоешма секретарьлары өчен семинар үткәрә. Семинарда теоретик мәсьәләләр һәм партиянең эчке эшләре буенча лекцияләр укыла. Рәсемдә: райкомның пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире иптәш НИКИТИН чираттагы занятиене үткәрә.

В. Лужбин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Контрольлек итү хокукы

Отчет-сайлау җыелышында Серго Орджоникидзе исемендәге завод коммунистлары парткомны предприятие администрациясенең эшенә контрольлек итү хокукын тиешенчә үтәмәве өчен тәнкыйтьләделәр.

Хәзер яңа сайланган партком, отчет-сайлау җыелышының карары нигезендә, эштәге бу төп җитешсезлекне бетерү буенча конкрет чаралар уздыра башлады. Март аенда партия оешмасы стахановчыларның завод күләмендәге слетын үткәрде. Слет ике завод арасында социалистик ярыш договоры төзү мәсьәләсен тикшерде, договор проэктын карап чыкты. Договорның төп пункты итеп республикабызның XX еллыгы көненә 6 айлык производство планын тулы үтәп килү бурычы куелды. Шушы договор нигезендә хәзер, цехларда, мастерскойларда, бригадаларда социалистик ярыш дулкыны күтәрелде. Бөтен коллектив үз өстенә алган йөкләмәне үтәү өчен көрәшә.

Партия оешмасы беренче чиратта игътибарны артта калып баручы участкыларга юнәлтте. Заводның транспорт бүлеге, партия оешмаларына сайлауларга кадәр, артта калып килә иде. Партком күптән түгел генә транспорт бүлеге буенча чыгарган карарның үтәлешен тикшерде. Транспорт бүлегендә эшне яхшырту буенча партком бүлекнең партия оешмасына конкрет ярдәм күрсәтте. Нәтиҗәдә транспорт бүлеге үзенең эшен сизелерлек рәвештә яхшыртты. Машиналарның эшләми торулары, аларның ватылу фактлары хәзер бетерелде диярлек.

Цех һәм бүлекләрнең партия оешмалары да партия контрольлеге эшен тамрыннан яхшырттылар. Ай ярым вакыт эчендә күп кенә цехларның начальниклары цех партия җыелышларында отчет ясадылар. Мәсәлән, секретаре Савильев, Дроков иптәшләр булган цех партия оешмалары, цех начальникларының отчетлары буенча кабул иткән карарларын оператив рәвештә тикшерә барулары нәтиҗәсендә, цехта эшне тамрыннан яхшыртуга ирештеләр. Коммунистлар производствода авангардлык ролен үтиләр. Мәсәлән, коммунистлардан Бабич, Смирнов, Фәйзуллин иптәшләр производствода үзләре алдынгы булулары белән бергә, цех партия оешмасының карарларын тормышка ашыру буенча да актив эш алып баралар. Партбюроның секретаре иптәш Савильев үзе мастерскойларның, бригадаларның эшләрен көндәлек рәвештә тикшереп, аларның эшләрендә системалы рәвештә ярдәм күрсәтеп килә. Хәзер бу цех күп кенә уңышларга иреште. Элек производство планын үтәүдә артта сөйрәлеп килгән мастерскойлар хәзер алдынгылар сафына чыктылар.

Ләкин эш барлык цехларда да болай яхшы куелмаган әле. Предприятие администрациясенең эшенә партия контрольлеген тормышка ашыруда алдынгы цех партия оешмаларының уңышлы эш тәҗрибәләре барлык оешмаларга да күчерелмәгән.

Партия оешмаларының тагын бер төп җитешсезлеге шунда ки, кайбер секретарьлар партия контрольлеген карар чыгару, боерыклар бирү белән генә чикләнә дип ялгыш аңлыйлар. Мәсәлән, секретаре иптәш Суровцева булган цех партия оешмасы алдында соңгы вакытта гаять катлаулы эш—цехта производствоны яңа баштан хәзерләү мәсьәләсе тора. Ә иптәш Суровцева, бу мәсьәләдә цехның теге яки бу участкысына конкрет ярдәм күрсәтәсе урында, административ күрсәтмәләр бирү белән генә чикләнә. Ә завод паркомы исә мондый секретарьларның эш стильләрен үзгәртүдә ярдәм итми.

Завод партия оешмасы менә бу кимчелекләрне бетерү өстендә конкрет эш алып барырга тиеш.

М. Гариф.

МАТБУГАТ КҮЗӘТҮ УРНЫНДА

РЕСПУБЛИКАБЫЗНЫҢ XX ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

Орденлы республикабызның данлыклы XX еллыгын производствода яңа уңышлар белән каршылау турында мехчылар чакыруы барлык хезмәт ияләренең политик һәм производство активлыгын тагын да югары күтәрүдә көчле этәргеч ясады. Бу ярышның массовый итүдә һәрбер завод, фабриканың, предприятиенең, һәрбер цех һәм бригаданың үзара ярыш эшләвен оештыруда күп тиражлы газеталарның тоткан роле гаять зур булды һәм ул шулай булып кала да.

Юбилей хөрмәтенә булган ярышны еллык җибәрүчә [illegible] фабрикаларында чыга торган „Мехчы" газетасы (редакторы иптәш Мансаутов) үзенең һәрбер номерында диярлек, ярыш материалларына зур урын бирә. Тегү яки бу фабрикада эшнең барышына анализ ясый. Газета алдынгыларның бай тәҗрибәләрен артта калучыларга күчерү эшенә, тәҗрибә белән уртаклашу оештыруга зур игътибар бирә. Күп станокта эшләүче Шакирова һәм [illegible] машинада эшләүче Шаткова иптәшләр турында бирелгән материалларда алар тәҗрибәсе киң яктыртыла.

„Спартакчы" (редакторы иптәш Корбанов) һәм ТАССР Җиңел Промышленность Халык Комиссариаты һәм тегүчеләр союзының Татарстан Өлкә Комитеты органы „Большевичка" (редакторы иптәш Галиуллин) газеталары да ярышны киң җәелдерүдә зур инициатива күрсәтәләр. Бу газеталар ярыш договорларының үтәлеше белән үз укучыларын әледән-әле таныштырып торалар, [illegible]

„Спартакчы" газетасы үзенең „Социалистик ярышка киң колач" дигән баш мәкаләсендә:

„Безнең комбинат коллективы белән Казандагы киез итек-фетр фабрикасы коллективы белән төзегән социалистик ярыш договоры барлык [illegible] тикшерелде. Ул зур күтәренкелек белән кабул ителде. Договор хәзер үзенең көчен күрде. Бурыч—алынган йөкләмәләрне практик рәвештә тормышка ашыру, цехлар арасында җәелә торган ярыш белән бергә, бригадалар, участкылар арасындагы ярышны оештыру, стахановча эшләү методына иң күп массаны тартудан гыйбарәт" дип язды. Шуннан соңгы һәрбер номерында газета ярыш турында [illegible] бирә.

„Спартак" комбинаты беренче квартал планын арттырып үтәде. Бу зур җиңүдә газетаның да оештыручылык роле зур булды.

„Большевичка" газетасы социалистик ярышта алган йөкләмәләрне намус белән үтәүчеләрне күрсәтү белән бергә, артта калучы участкыларны тәнкыйть уты астына ала. Производство планын арттырып үтәү өчен фабрикаларда гаять зур эшке мөмкинлекләр барлыгын конкрет фактлар белән раслый.

„Тегү фабрикалары беренче квартал планын арттырып үтәделәр. Ләкин бу безгә тынычланырга хокук бирми әле. Бездә артта калучы цехлар һәм участкылар да юк түгел... Нормаларын үти алмаучыларның стахановча эшләүләренә ирешкәндә, машиналарның эшсез торуларын бетерүгә ирешкәндә, уңышларыбыз тагын да зуррак булыр иде" ди газета (№ 16) һәм бу өлкәдәге тоткарлыкларның [illegible] таләп итә. Соңгы бер ай эчендә генә дә „Большевичка" газетасы республикабызның XX еллыгы алдыннан алган темага 11 мәкалә урнаштырган.

Кызганычка, югарыда күрсәтелгән газеталар соңгы вакытларда производство мәсьәләләрен [illegible] Социалистик ярыш мәсьәләләрен [illegible] Ләкин, шуның белән бергә, бу өлкәдә үз бурычларын [illegible] газеталар да юк түгел.

„Вахитовчы" газетасы (редакторы иптәш Тажиева) моның мисалы булып тора. Комбинат коллективы мехчылар чакыруына җавап итеп, ярты еллык планны 25 июньгә үтәргә [illegible] иде. Газета бу йөкләмәнең үтәлешен системалы рәвештә [illegible]

Комбинат беренче квартал планын бары тик 82 процентка гына үтәде. „Вахитовчы" газетасы „комбинат коллективы республикабызның XX еллыгына лаеклы хәзерләнә" дип шапырына. 8 март көнне хабарчылар тарафыннан үткәрелгән, газетаның 14 нче номерында урнаштырылган [illegible]

Әйрем рекордлар белән генә мавыкмаска, а барлык участкыларда да стахановча эшләүләренә ирешергә—газеталар массаны әнә шул бурычларны уңышлы үтәү тирәсенә тупларга тиешләр.

1940 нчы елгы күргәзмәдә нинди яңалыклар булачак

Һәрбер көн безне 1940 нчы елгы Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенең ачылуына якынайта. Миллионнарча колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар, совхоз һәм МТС эшчеләре, социалистик игенчелекнең белгечләре һәм оештыручылары аны түземсезлек белән көтәләр.

Тулы булмаган саннарга караганда, 2.700 район, 133.600 колхоз, 4.500 МТС, 1.300 совхоз, 230 меңнән артык бригада, 500 мең звено, ярты миллионнан артык авыл хуҗалыгы алдынгылары, белгечләре һәм оештыручылары быел күргәзмәгә катнашу хокукы өчен социалистик ярышка кушылдылар. Март башыннан ук инде күргәзмәдә катнашырга теләүчеләрдән 410 меңнән артык гариза керде. Гаризалар агылуы тиз үсә бара, катнашучыларның гомуми саны, һич шиксез ярты миллионнан артачак.

Красноярск крае бөртекле культуралар буенча киң рәвештә күрсәтү өчен бөтен Хакассия автономияле өлкәсен күргәзмәгә җибәрә.

Соңгы өч ел эчендә совхозлары һәм колхозлары иген уңышын һәр гектардан уртача 11,7 центнер алуга ирешкән Хакассия Себер залының „Орлык" павильонына үзенең экспонатларын куячак. Бу залның художество ягыннан бизәлгән үзәк установкасы аңа багышлана. Рәсемнәр, скульптура, фотографияләр, натураль экспонатлар Хакассия колхозчыларының казанышларын, элек патша Россиясенең ярым колониясе булган бу өлкәнең хәзер гөрләп үсүен күрсәтәчәкләр.

Күргәзмәдә катнашу өчен Украина үткән елны дуңгыз асраучылык буенча зур уңышларга ирешкән Полтава өлкәсенең барлык 2.500 колхозын такдим итә. Быел күргәзмәдә тулысынча күрсәтеләчәк районнар саны шактый артачак.

Үткән елны аларга алты стенд багышланган булса, быел андый стендлар саны 43 кә җитәчәк. „Орлык" павильонының үзендә генә дә дүрт районны киң рәвештә күрсәтү күздә тотыла. Ростов өлкәсенең Сальск районы алар арасында аеруча кызыксыну тудыра. „Экскурсантлар һәм күргәзмәне карарга баручылар алдынгы агрономия һәм машина техникасы белән коралланган колхозчыларның корылыкны чигенергә мәҗбүр иткәнлекләрен бу районның үрнәгендә күрәчәкләр. Зур паннолар, күп сандагы диаграммалар, фотолар, таблицалар, модельләр, натураль экспонатлар күргәзмәне карарга баручыларга Сальск районы колхозчылары тарафыннан кулланыла торган стахановча агротехниканың бөтен комплексы белән ныклап танышырга ярдәм итәчәкләр.

Харьков өлкәсенең Зачепилов районы да күргәзмәдә катнашу хокукын яулап алды. Бу районда колхозчыларның укуы яхшы оештырылган. Күп сандагы стахановчылар мәктәпләрендә алар авыл хуҗалыгы алдынгыларының тәҗрибәләрен өйрәнәләр, алдынгылар кулланган эш методларын үзләштерәләр. Уку колхозчыларга кырларда иген уңышын шактый күтәрүгә, терлекчелекнең продуктлылыгын арттырыруга ирешергә ярдәм итә.

Социалистик терлекчелек шактый киңрәк һәм тулырак күрсәтеләчәк. Җәмагать терлекчелеген үстерү турында партиянең һәм хөкүмәтнең карарларын үтәү өчен көрәштә колхозлар һәм совхозлар тарафыннан ирешелгән уңышлар павильоннарның стендларында һәм күргәзмәнең фермаларында ачык чагылачаклар.

„Авылда яңалык" бүлегенең үзендә генә дә фермалар үткән елгыдан ике тапкыр артыграк күрсәтеләчәк. 1940 нчы ел күргәзмәсендә 5 меңнән артыграк терлекләр һәм кошлар күрсәтергә уйланыла.

Җанлы экспонатларны сайлау эше хәзергә тәгәлләнмәгән булса да, күргәзмә өчен билгеләнгән терлекләр арасында гаять кыйммәтле терлекләр барлыгын әйтергә мөмкин.

Орденлы „Красный чабан" совхозы Москвада күрсәтү өчен Ватаныбызда үстерелгән „Аскания рамбульесе" нәселле тәкә җибәрәчәк. Сигез пот авырлыгындагы бу тәкә ел әйләнәсендә югары сортлы 18 килограмм йон бирә. Бу йон сигез костюм өчен бик яхшы материя эшләп чыгарырга җитә. „Чирвленные буруны" совхозы тарафыннан күргәзмәгә җибәрелә торган икенче тәкәнең бер ел эчендә биргән йонынннан иң яхшы сыйфатлы егерме метр чамасы йон ткане хәзерләргә мөмкин.

Киров өлкәсенең „Сталинский путь" колхозы үзенең терлекчелек фермаларындагы башка экспонатлар белән бер рәттән гәүдәсенең озынлыгы 196 сантиметр булуы ягыннан рекорд алган „Нева-П" исемле ана дуңгызны күрсәтәчәк. Дуңгыз асраучылык фермаларының үткән елгы экспонатлары арасында „Секрет" исемле ата дуңгыз иң озын гәүдәле—192 сантиметр озынлыгында иде.

Күргәзмәне караучылар „Механизация" павильонында яңа һәм кызыклы күп кенә нәрсәләр күрәчәкләр.

Хәзер Главсельмашның 17 заводы күргәзмәдә күрсәтү өчен 213 экспонат машина хәзерли, аларның 73 е бөтенләй яңа машиналар. Алар арасында „Сталинец-5" дигән 30 футлы комбайнның эксперименталь үрнәкләре, растениепитатель, ефремовча чәчүлекләр өчен рәт аралары 50 миллиметр киңлегендәге тар рәтле чәчү машинасы, үлән чәчкеч машиналары бар. Запорожьедагы „Коммунар" заводында күргәзмә өчен киң колачлы (40 футлы) яңартып эшләнгән, егылган ашлыкны урырга мөмкинлек бирә торган мотовилолы комбайн, шулай ук техник культураларны урып-җыю өчен җайланган комбайн хәзерләнә.

Одессаның Октябрь революциясе исемендәге заводында эшләнгән һәм чөгендерне җинау эшен механикалаштыра торган чөгендер комбайны зур кызыксындыру тудыра. Воронеж өлкәсеннән килгән орденлы тракторчылар группасы, Харьков трактор заводының 1939 нчы елгы күргәзмәдә күрсәтелгән экспонатларын карагач, тракторның төрле детальләренә зур гына үзгәрешләр кертергә такдим иткән иде. Бу заводның яңа экспонатлары хәзер инде атаклы тракторчыларның такдимен искә алып эшләнгәннәр.

Харьковтагы „Серп һәм Молот" заводы „ВИМ-СМ-1" маркалы орлык чистарткыч машина урнына быел тагын да җиренә җиткеребрәк эшләнгән „ВИМ-СМ-2" машинасын күрсәтәчәк. Аның белән бөртекле культураларны гына түгел, бәлки үлән һәм тары орлыкларын да чистартырга мөмкин. Аның эшләп чыгарышы „ВИМ-СМ-1" машинасыныкыннан 40 процент югарырак. 1939 нчы елгы күргәзмәдә булучыларның такдиме буенча орлык чистарту машинасы триерының конструкциясе яхшыртылды. Ул шактый җиңел итеп эшләнгән, аның монтажы гадиләштерелгән, бу—металлга зур экономия бирә.

Колхозларда тракторчыларның яңа гүзәл кадрлары үсте. Алар арасында хатын-кызлар да аз түгел. Күргәзмәнең барлык павильоннарындагы стендлар машиналаштырылган игенчелекнең бу гүзәл мастерларының эшен күрсәтәчәкләр.

Моннан берничә ел элек Чкалов өлкәсе, Бузулук районының Вильямс исемендәге МТС ы тракторчысы Ефросинья Дробышева авылдагы үзенең дус кызларын тракторчылар курсында укуга тартырга, аларны хезмәтнең стахановча методларына өйрәтергә вәгъдә биргән иде. Орденлы Дробышева үзенең вәгъдәсен намус белән үтәде. Үткән елны инде Вильямс исемендәге МТС та 48 тракторчы кыз эшләде. Дробышеваның шәкертләре югары күрсәткечләргә ирештеләр һәм аларның утызы 1940 нчы елгы күргәзмәдә катнашуга мактаулы хокукны яулап алды.

„Торф" павильонының яңа стендлары кызыклы һәм үрнәкле булачаклар. Аларның берсендә Белоруссиянең „Речица" совхозының казанышлары күрсәтеләчәк. Соңгы өч ел эчендә совхоз ике мең гектар сазлыкны киптерде һәм культуралы иген басуына әйләндерде. Горький өлкәсе, Городец районының Киров исемендәге колхозы торф ашламаларының киң кулланылуын күрсәтәчәк. Москва өлкәсе, Мытище районының „Памяти Ильича" колхозы яшелчәләр үстерү өчен торф чүлмәкләре хәзерләүне һәм куллануны күрсәтәчәк. Алар ярдәме белән үрентеләрне күчереп утыртуны җиңелләштереп, үсемлекләрнең үсү шартларын яхшыртып һәм уңышны күтәреп була.

Авыл хуҗалыгын химияләштерүнең үсүе һәм бу эштәге алдынгыларның казанышлары үткән елга караганда шактый тулырак күрсәтеләчәк.

Үз хуҗалыкларын яңа җирләрдә алып баручы күчеп утырган колхозларның тормышлары һәм эшләре күп кенә стендларда яктыртылачак.

1940 нчы елгы күргәзмә совет авылының культурасын бөтен бөеклеге һәм төрлелеге белән күрсәтәчәк. Баш павильонда аңа махсус зал багышланачак. Күргәзмәне караучы мондагы макетларда һәм фотоларда үрнәк мәктәпләрне, паркларны, больницаларны, бала тудыру йортларын, ясләләрне, уку өйләрен, хәзер һәрбер колхозда булган бөтен нәрсәләрне күрәчәк. Аерым павильон колхозчылар арасында физкультура һәм спорт үсешен күрсәтүгә багышлана.

1940 нчы елгы күргәзмәне үткән елгы күргәзмәдән аерачак яңалыкларны кыска гына санап чыгу да мөмкин түгел. Күргәзмәдә булучы бу яңалыкны күргәзмәнең һәрбер павильонында, барлык ачык участкыларында һәм бакчаларында табачак.

Быелгы күргәзмә авыл хуҗалыгыбызның казанышларын тагын да киңрәк, тулырак һәм ачыграк яктыртачак һәм колхоз строеның яңа җиңүләренә булышлык итәчәк.

И. Ганов.

Агрономия киңәшләре

УҖЫМНАРНЫ ТӘРБИЯЛӘҮ ТУРЫНДА

Үткәрелгән соңгы күзәтүләр, күп урыннарда уҗымнарның яхшы хәлдә булуларын, ә кайбер урыннарда исә көчсез булуларын күрсәтте. Иген уңышына кимчелек килмәсен өчен мондый участкыларда уҗымнарны яз көне җирле һәм минераль ашламалар белән әлбәттә тукландырырга кирәк.

Уҗымнарны иртә язда тукландыру аларның тиз үсүләре һәм ныгулары өчен бик файдалы чара булып тора. Тукландыру беренче чиратта орлыклык участкыларда һәм кар астыннан көчсез булып чыккан участкыларда үткәрелергә тиеш.

Казан селекция станциясе тарафыннан үткәрелгән тәҗрибәләргә караганда уҗымнарны иртә яздан тукландыру иген уңышын гектарына 3—4 центнер арттыра. Мәсәлән, 1938 нче елны тукландырылган участкыда бодайның һәр гектарыннан уртача 12,6 центнер уңыш чыкты. Ә сернокислый аммоний (гектарга 2,3 центнер) һәм суперфосфат (гектарга 2,5 центнер) белән тукландырылган участкы гектарыннан 17,64 центнер уңыш бирде.

Уҗымнарны язгы тукландыруның көчле чара булуы колхозларда үткәрелгән тәҗрибәләрдә дә бик ачык күренә. Норлат районының „Совет“ колхозында 1937 нче елны яз көне тукландырылмаган участкыда арыш гектарыннан бары 16,6 центнер уңыш биргәндә, гектарына 2,3 центнер исәбеннән сернокислый аммоний белән тукландырылган участкы гектарыннан 20,4 центнер уңыш бирде. Шул ук колхозда гектарына 2,5 центнер исәбеннән суперфосфат белән тукландыру үткәрелгән участкыда гектарыннан 21,7 центнер уңыш чыкты. Бу ашламаларның икесе белән дә (югарыда күрсәтелгән дозаларда) тукландырылган участкыда гектарыннан 23,5 центнер уңыш алынды. 1938 нче елны Тымытык районының „Эконом“ колхозында гектарына 6 тонна хисабыннан тирес сыекчасы белән тукландырылган арыш гектарыннан 23,3 центнер уңыш бирде, ә тукландырылмаган участкыларда уңыш бары 18 центнер булды.

Уҗымнарны иртә яздан беренче кат тукландыру участкыларда су бетү артыннан ук үткәрелергә тиеш. Чөнки бу вакытта уҗым культуралары туклыклы азыкка, барыннан да элек азотка, бигрәк тә мохтаҗ булалар. Казан селекция станциясе уҗымнарны тукландыру эшендә сроклар буенча да тәҗрибәләр үткәрде. Мәсәлән, 1938 нче елны кар китүгә үк суперфосфат һәм сернокислый аммоний белән тукландырылган участкыларда уҗым бодаеның гектарыннан уртача 19,2 центнер уңыш чыкты, ә 13 көн соңгарак калып һәм шул ук ашламалар белән тукландырылган участкыда гектарыннан бары 18 центнер уңыш алынды. Шуңар күрә, кош тизәге (коры хәлендә), суперфосфат, калий тозы һәм сернокислый аммоний кебек ашламалар белән туфрак өсте тулысынча эреп бетмәгән чорда ук тукландыра башларга кирәк.

Уҗымнарны тукландыру өчен барлык өч төр ашлама да (азотлы, фосфорлы һәм калийлы ашламалар) кулланыла. Тукландыру өчен азотлы ашламалардан аммиачный селитраны һәм сернокислый аммонийны кулланырга мөмкин. Тукландыру өчен фосфорлы ашламалардан тик суперфосфатны гына кулланырга кирәк. Калийлы ашламалардан исә 40 процентлы калий тозы кулланыла.

Тукландыру өчен җирле ашламалардан—кош тизәгеннән, тирес сыекчасыннан һәм башкалардан киң рәвештә файдаланырга кирәк.

Язгы тукландыру өчен ашлама дозасы уҗымның хәленә һәм туфракның туклыклы матдәләр белән никадәр тәэмин ителгән булуына карап билгеләнә. Электән ашлама кертелгән һәм уҗымның торышы да яхшы булган участкыларга карата тукландыру дозалары уҗымы начар һәм көздән ашланмаган участкыларга чагыштырганда, билгеле, кимрәк алына. Уҗымны тукландыру өчен һәр гектарга 25—35 килограмм азот, һәрберсе 30—45 килограммнан фосфор кислотасы һәм калий кертергә киңәш бирелә. Димәк, ашламага күчереп исәпләгәндә, һәр гектарга 0,75—1,0 центнер аммиачный селитра, яисә 1,25—1,75 центнер сернокислый аммоний, 2—3 центнер суперфосфат һәм 0,75—1,0 центнер калий тозы кирәк була.

Тукландыруны иртә туң вакытта, ашлама машиналары белән, алар булмаганда сошниклары алынган гади чәчү машиналары белән үткәрергә кирәк.

Тукландыру өчен кош тизәге (коры хәлендә) көлсыман туфракларда гектарга 7—8 центнер, ә кара туфракта 5 центнер алына. Тирес сыекчасы кара туфраклы участкыларда гектарына 5 тонна, көлсыман туфраклы участкыларда 7 тонна алына. Тирес сыекчасы уҗымны тырмалау алдыннан сиптерелә. Бу ашлама бер өлеш сыекчага 2—3 өлеш су кушып хәзерләнә.

Тукландыру өчен кертелгән минераль ашламалар басуга тырма белән чыгып эшли башлау мөмкин булган көнне үк тырма белән күмдерелергә тиешләр. Тырмалау зиг-заг тырмалар белән, рәтләргә аркылы булырга тиеш. Туфрак юеш чакта тырмаларга ярамый. Шулай ук тырмалауны бик соңга да калдырырга ярамый. Тырма тешенә балчык ябышмый башлагач та тырмаларга керешергә мөмкин. Туфрагы нык утырган участкыларда ике эздән, ә җиңел туфраклы һәм уҗымы көчсез булган участкыларда бер эздән тырмаларга киңәш бирелә.

А. А. Капитонов.

Казан Дәүләт Селекция станциясенең фәнни өлкән сотрудникы.

ТАТАРСТАН АССР ның БАРЛЫК РАЙОН ГАЗЕТАЛАРЫ РАБОТНИКЛАРЫНА

Актаныш районында чыга торган „Колхоз ударнигы“ газетасының редакция һәм типография работниклары мөрәҗәгате

Социалистик төзелешнең барлык этапларында да большевистик матбугат партиябезнең иң көчле һәм иң үткен коралы булды. Хәзерге чорда—коммунистик җәмгыят төзү эпохасында, хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү, кешеләрнең аңында капитализм калдыкларын бетерү хәл иткеч бурыч булып әверелгәндә аның әһәмияте тагын да үсә.

Район газеталарының эшен, аларның пропагандистлык, агитаторлык һәм оештыручылык ролен ВКП(б) ның XVIII нче съезды тарафыннан куелган таләпләр югарылыгына күтәрү өчен, без, Актаныш районында чыга торган „Колхоз ударнигы“ газетасы редакциясенең сотрудниклары район газеталарының республика ярышын оештырырга тәкъдим итәбез. Бу ярышка кушылып, без, түбәндәге социалистик йөкләмәләрне алабыз:

1. Масса белән газетаның элемтәсен барлык чаралар белән ныгытырга. Партия, комсомол, совет һәм хуҗалык работникларын, авыл хуҗалыгы алдынгыларын, интеллигенция вәкилләрен газетага даими рәвештә актив язышуга тартырга; аларның материаллары газета битләрендә урыннардагы темаларга язылган барлык материалларның кимендә 80 процентын алырга тиеш. Районның хуҗалык һәм культура төзелешенең конкрет мәсьәләләрен тикшерү өчен төрле тармак работникларының редакция янында киңәшмәсен чакыруны кулланырга. Редакциянең эш планын һәм редакция тарафыннан үткәрелә торган чараларны редакциядән тыш авторлар активы белән системалы рәвештә тикшерергә. 1940 нчы елны газета укучыларның 5 тапкыр конференциясен үткәрергә.

2. Партия тормышы һәм партия пропагандасы мәсьәләләрен һәр яклап һәм тирәнтен яктыртырга, партия оешмаларының, партия тарихын үзлекләреннән өйрәнүчеләрнең эш тәҗрибәсен, агитация-масса эше тәҗрибәсен бергә тупларга.

3. Сталинчыл уңыш өчен, социалистик терлекчелекнең продуктлылыгын күтәрү өчен көрәштә, Мордовия һәм Чувашстан республикалары белән төзелгән ярышта алынган йөкләмәләрне үтәүдә, Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашу хокукы яулап алуда партия һәм совет оешмаларына, колхозларга һәм колхозчыларга конкрет ярдәм күрсәтергә. Авыл хуҗалыгы алдынгыларының тәҗрибәсен тупларга, аларны барлык чаралар белән популярлаштырергә, аларның эш методларын районның барлык колхозларына, МТС ларына һәм совхозларына киң җәелдерүгә ирешергә.

4. Районның тормышын, хезмәт ияләренең культура һәм политик үсешен, мәктәпләрнең, клубларның һәм уку өйләренең эшен нык яктыртырга. Укучыларны республикада, Советлар Союзында һәм чит илләрдә бара торган әһәмиятле вакыйгаләр белән даими рәвештә таныштырып торырга.

5. Түбәнге матбугатның эшен активлаштырырга. Моның өчен стена газеталары редакторларының һәм эшче-авыл хәбәрчеләренең читтән торып укуын оештырырга, бу укуларга 40 кешене тартырга; стена газеталары редакторларыннан 80 кешене район газетасы янында 5—10 көнлек производство практикасы аркылы үткәрергә; өч айга бер тапкыр стена газеталары редакторларының һәм эшче-авыл хәбәрчеләренең бер көнлек семинар-киңәшмәсен үткәрергә, аларда түбәнге матбугатның һәм эшче-авыл хәбәрчеләренең чираттагы бурычларын, иң яхшы стена газеталарының эш тәҗрибәсен, аерым эшче-авыл хәбәрчеләренең иҗад тәҗрибәсен өйрәнергә; айга ике тапкыр стена газеталарын күзәтү басып чыгарырга, стена газеталары редколлегияләренең ярышын оештырырга.

6. Оборона мәсьәләләрен яктыртуга игтибарны көчәйтергә. Редакциянең һәм типографиянең һәрбер сотруднигының бер хәрби специальностьны (стрелок, пулеметчы, гранато-метчик һ. б.) үзләштерүенә һәм 1—2 оборона значогына нормалар тапшыруына ирешергә.

7. Газетаны укучыларга һәм эшче-авыл хәбәрчеләренә әдәби иҗад ярдәме күрсәтү өчен редакция янында әдәбият түгәрәге оештырырга.

8. Газетаның оформлениесен һәм газетада урнаштырыла торган материалларның сыйфатын яхшыртырга, ялгышлар һәм хәреф хаталары җибәрүне бөтенләй бетерүгә ирешергә.

Ф. ЗАҺИДУЛЛИН, Җ. ХИСМӘТУЛЛИНА, Ш. ШӘЙГАРДАНОВ, М. БОРҺАНОВА, Б. НУРИЕВ, Н. САБИРОВА, Ф. ХАҖИЕВА, Т. ХӘСӘНОВА, З. КОРБАНОВА, З. САБИРОВ, М. ШАКИРОВ.

(Актаныш районында чыга торган „Колхоз ударнигы“ газетасы редакциясе һәм типографиясе сотрудниклары).

Лаеш урта мәктәбенең пионер отряды советы социалистик ярыш договорының үтәлеше йомгагын тикшерә.

С. Чиколкин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

СМЕНА АРАСЫНДА

Беренче сменада укучылар дәресләрне тәмамлап өйләренә таралганнар. Икенче сменада дәресләр башланырга 40—50 минут вакыт бар әле. Димәк, мәктәп эче тып-тын, класслар буш һәм яхшы итеп җилләтелгән булырга, аларның форточкаларыннан язгы саф һава аңкып торырга тиеш. Ә мәктәп җитәкчеләре икенче смена укучыларын каршылау өчен хәзерләнә торганнардыр!..

Молотов районындагы 18 нче урта мәктәпнең ишеген ачканда әнә шулар күз алдына килә. Чөнки бу вакытта сәгать 12 тулып бары 8 генә минут киткән иде. Ә икенче сменада укулар һәр сәгать бердә башлана. Шулай булгач югарыдагы фикерләр һәр кемнең башына килергә мөмкин. Ләкин бу уйлар озакка бармады. Ишекне ябу белән алар юкка чыктылар. Икенче каттан бер кыз баласының елап төшүе һәм югары катта уннарча балаларның кычкырулары, көлешүләре бу уйларны тараттылар.

Чыннан да мәктәп эчендә балалар шактый күп күренә. Аларның кайберләре классларга керел китапларын, дәфтәрләрен актаралар, ә кайберләре коридор буйлап йөгерешәләр, классларга кереп парта өсләреннән сикерешәләр, бер-берсе белән тарткалашалар, кыскасы, дөнья күтәрәләр.

Шулай итеп ике смена арасындагы бер сәгать вакыт балаларның шаярулары белән үтеп китә, мәктәп тавышлы. Бу вакытта мәктәп директоры да, укыту бүлеге мөдире дә, комсомол һәм пионер оешмалары да мәктәпкә җитәкчелек итмиләр.

Менә дәрес вакыты җитә, звонок тавышлары, укучылар коридордан, укытучылар үзләре өчен билгеләнгән бүлмәдән классларга керәләр. Димәк, мәктәптә тынлык башланырга тиеш...

Ләкин мәктәптә шау-шу тукталмый, шаяру, көлешү дәвам итә. Без укыту бүлеге мөдире иптәш Таһировка сорау бирәбез:

— Бу тавыш сезнең мәктәпкә каян ишетелә соң?

Ул елмаеп җавап бирә: „Чит тавыш түгел, үзебезнең тавыш, чөнки бүген бер укытучы авыру сәбәпле килмәгән“.

Шуннан соң тагын сорау бирәбез:

— Сезнең мәктәптә махсус куелган пионер вожатый бар, ул шушындый вакытларда балалар арасында масса-аңлату эшләре оештырмыймени?

Иптәш Таһиров бик тартынып кына җавап бирә: „Безнең вожатыебыз гомумән эш...“.

Биредә тартынып торасы юк иптәш Таһиров, сезнең вожатыегыз эшләми һәм эшләргә дә теләми. Шул ук вакытта мәктәп җитәкчеләре, сез үзегез дә, мондый вакытлардан файдалану турында ныклап уйламагансыз. Әгәр дә сез дәрескә алдан килүче балалар арасында һәм менә бүгенге кебек (9 нчы апрель) укытучылар тәге язсә бу сәбәп белән дәрескә килмәгән укучылар арасында интешлеру белән дәресләр, тәрбиябә укучыларга оештырсагыз иде, урта мәктәп укучыларын фәннәр югары баскычлары көткәнлекне аңлатсагыз иде, моннан сезнең мәктәп өлгереш күрсәткечләре күп тапкырлар яхшырак һәм югарырак булыр иде. Беренче чиректә 64 процент өлгергән белән, икенче чиректә 73,7 процент һәм өченче чиректә 78 процент өлгереш белән канәгатьләнми булыр идегез. Шул ук вакытта бер класста ике ел калучылар да 65 ләп саналмас иде.

Гомумән бу мәктәптә дисциплинаның түбән булуын һәм үзара мөнәсәбәтнең начар торуын әйтергә кирәк. Дәрес вакытында сөйләшү, шаяру, сагыз чәйнәү, укытучы әйткәннәрне ишетмәскә тырышу, өйгә бирелгән заданиеләрне үтәмичә килү кайбер укучыларга гадәт булып киткән. Бу нәрсәләр IV нче „б“, V нче „б“ һәм VII нче „б“ классларында аеруча нык сизелә. Шулай булгач бу классларда укучыларның өлгерешләре башка классларга караганда күп түбән булуы гаҗәпмени.

Мәктәптә бик тырышып эшләүче укытучылар һәм тырышып укучы балалар да бар. Мәсәлән, II нче „а“ классы 100 процент өлгереш бирел килә. Бу классның җитәкчесе иптәш Корбангалиева сокланырлык үрнәкләр күрсәтә. Ләкин мондый алдынгыларның уңышлы тәҗрибәләрен башкаларга күчерү белән начар шөгыльләнәләр. Ә бит бу бурыч алдынгылардан үрнәк алу һәм шуңа тәрбиясен үзләштерүен, гомуми күтәрелешкә ирешү. Менә бу нәрсәне 18 нче мәктәп җитәкчеләре исләреннән чыгарганнар.

Уку елының хәл иткеч айлары бара. Дүртенче чирек азагында еллык эшкә йомгак ясалачак. Мәктәп коллективы җитешсезлекләрнең сәбәпләрен өйрәнергә һәм аларны бетерү өчен иң кискен чаралар күрергә тиеш. Бу мәктәпнең эшенә комачаулый торган төп җитешсезлек—ул, дисциплинаның начар булуы. Димәк, барыннан да элек, дисциплинаны ныгытырга кирәк. Бу инде укучылар арасында коммунистик тәрбия эшләрен көчәйтергә, комсомол һәм пионер эшләрен ныклы юлга салырга кирәк дигән сүз. Үз эченә 510 укучыны һәм 26 укытучыны берләштергән 18 нче мәктәп коллективыннан хәзер әнә шул таләп ителә.

М. Ш.

Терлекчелек күтәрелештә

Калинин районы терлекчелек буенча республикабызда алдынгы районнарның берсе. Социалистик терлекчелекне үстерүдә яхшы күрсәткечләре өчен үткән ел бу районга Татарстан хөкүмәтенең күчмә кызыл байрагы тапшырылган иде.

Районның колхоз фермаларында 1940 нчы елның 1 нче январена терлекләр саны түбәндәгечә: 2.987 баш сыер, 8.788 баш сарык, 2.101 баш дуңгыз. Атлар саны 8.535 башка җиткән. Колхозчыларның үз хуҗалыкларында 7.440 баш мөгезле эре терлек, 16.383 баш сарык, 2.205 баш кәҗә һәм 115 баш дуңгыз бар.

Җәмагат терлекләренең саны 1938 нче елның 1 нче январена булган саннарга чагыштырганда, атлар 23,3 процент, мөгезле эре терлекләр 26,4 процент, сарыклар 53,2 процент, дуңгызлар 60,8 процент арткан. Өченче бишьеллыкның ике елы эчендә җәмагат терлекләренең үсеш динамикасы әнә шундый.

1939 нчы елда дәүләт планын үтәү атлар буенча 103 процент итеп, мөгезле эре терлекләр буенча 101 процент, сарыклар буенча 107 процент итеп үтәлгән.

Яш терлекләрне тәрбияләп үстерү буенча да күрсәткечләр канәгатьләнерлек. Колыннар үстерү планы 1.212 урнына—1.447, бозаулар 1.025 урнына—1.076, сарык бәрәннәре 2.787 урнына—3.225 баш алып үстерелгән. Һәр 100 баш сарыкка уртача 135 бәрән һәм һәр ана дуңгызга уртача 12,3 дуңгыз баласы туры килә.

„Колхозларда җәмагат терлекчелеген үстерү чаралары турында“ ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Халык Комиссарлары Советының карары чыкканнан соң эре мөгезле терлекләр буенча 12, сарыкчылык буенча 17, дуңгыз асраучылык буенча 10 яңа ферма оештырылган. Бу чараны үткәрү планы да арттырып үтәлгән. Терлекләрне үрчетү һәм алардан продукция алу буенча аерым фермаларда тагын да яхшырак күрсәткечләр бар. „Кызыл Юл № 1“ колхозы фермасында үткән ел һәр 100 сарыктан 185 баш, „Партизан“ колхозы фермасында 165 баш бәрән үстерелгән. „Правда“ колхозының товарлыклы-сөтчелек фермасында һәр сыердан уртача 1.492 литр сөт савып алынган.

Үрәзмәт авылы Ленин исемендәге колхозның дуңгыз асраучылык фермасында дуңгызлар караучы Миңлеәхмәт иптәш Фазлеевның эш күрсәткечләре күпләргә үрнәк булырлык. Ул соңгы ике ел эчендә үзе карый торган һәр ана дуңгыздан уртача 24 дуңгыз баласы алып үстергән. Аның бу эштә 6 еллык тәҗрибәсе бар. Ул дуңгызларны карау, тәрбияләү техникасын яхшы үзләштергән. Иптәш Фазлеев үткән ел Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашып, Күргәзмә Комитеты тарафыннан кече алтын медаль белән бүләкләнгән. Ул күргәзмәгә катнашу турында быел да гариза биргән.

Районда күп кенә башка колхозларның терлекчелек фермаларында да иптәш Фазлеев кебек яхшы эш үрнәкләре күрсәтүче алдынгылар бар. Үткән ел терлекчелек алдынгыларыннан 28 кеше Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашкан булса, быел күргәзмәгә катнашуны сорап 55 кеше гариза биргән.

Бу саннар һәм фактлар Калинин районының партия, совет оешмаларының, колхозларының социалистик терлекчелекне үстерү өчен ныклы көрәш алып барулары турында сөйлиләр. Ләкин бу уңышлар район оешмалары һәм колхоз җитәкчеләренә, бигрәк тә район җир бүлеге работникларына тынычланып калу хокукын бирми. Ә фактта исә, соңгы вакытта бу нәрсә биредә нык сизелә. Шуның аркасында бу өлкәдә әле күп кенә кимчелекләр бар.

Терлекләрнең нәселләрен яхшырту, аларның продукция бирүчәнлеген күтәрү өчен көрәш тиешле югарылыкка куелмаган. Товарлыклы-сөтчелек фермаларында үткән ел һәр сыердан уртача 837 литр гына сөт савып алынган. Өч республика арасында төзелгән социалистик ярыш договоры буенча алынган йөкләмәләргә караганда бу сан бик түбән әле. Фермалардагы терлекләргә профилактик чаралар үткәрүне оештыру һич тә канәгатьләнерлек түгел.

Районда ике ветеринария врачы һәм 2 ветфельдшер җитми.

„Ленин бүләге“, „НОТ“ кебек байтак колхозларның фермаларында сыерлар һәм яш терлекләр, сарыклар аерым караучыларга беркетелмәгән. Шул сәбәпле терлек караучыларга хезмәт көннәре инструкция буенча язылмый. Яш терлекләрне карау, тәрбияләүгә әһәмият бирмәү аркасында „Марс“ һәм „Октябрь“ колхозларында яш терлекләрнең үлү фактлары да булган.

Азык базасын ныгыту терлекчелекне үстерүдә иң әһәмиятле чараларның берсе. Ләкин бу эштә дә әле шактый кимчелекләр бар. Районның терлек азыгы балансы киеренке. Шуңа карамастан, булган азыкны саклап тотмау, рацион буенча ашатмау аркасында берничә колхозда азык җитмәүчелек килеп чыга („Марс“, „Искра“ колхозлары һ. б.). Шул ук вакытта терлек азыгы алу өчен дәүләт тарафыннан бирелгән ссудалар файдаланылмый яткырыла. Быел бирелгән 15 мең сум ссуданың әле 1.400 сумы гына файдаланылган. Үткән елда да терлекчелекне яхшырту чаралары өчен дәүләт тарафыннан бирелгән ссуданың 30 мең сумы файдаланылмый калган.

Терлек азыгы өчен быел район колхозларында 1.000 гектар клевер, 500 гектар көнбагыш, 350 гектар тамыр азык чәчелергә тиеш. Яз җитте. Ә клевер, көнбагыш орлыклары тулысынча хәзерләнмәгән. 12 центнер тамыр азык орлыгы җитми.

Хәзер колхозларның һәм район оешмаларының игтибары терлек азыгы базасын булдыру өчен язгы чәчүне яхшы үткәрүгә, яш терлекләрне саклап калуга, көтүлекләрдән дөрес файдалануга, чаптыру кампаниясен яхшы итеп оештыруга юнәлергә тиеш.

„Авыл хуҗалыгы продуктларын хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр“ турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Халык Комиссарлары Советы карары колхозларның җәмагат хуҗалыгын күтәрүдә партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан гаять зур мөмкинлекләр тудырылуның бөек документы. Бу карар колхозларның җәмагат терлекчелеген, кошчылыкны тагын да үстерүдә һәм ат асраучылыкны күтәрүдә көчле этәргеч булачак.

Районның партия, совет оешмалары җитәкчеләре колхозчылар массасының киң инициативасына таянып, аларның бай тәҗрибәләреннән һәм инициативасыннан файдаланып, бу карарны практик тормышка ашыру нигезендә социалистик терлекчелекнең тагын да көчлерәк күтәрелешен тәэмин итәргә тиешләр.

А. Вәлиев.

(„Кызыл Татарстан“ның махсус хәбәрчесе).

Район җитәкчеләре оныткан мөһим бер эш турында

Мамадыш районында яшьләргә физик тәрбия бирү, бигрәк тә МТС ларда, совхозларда, предприятиеләрдә һәм колхозларда физкультура эше гадәттән тыш начар куелган. Физкультурниклар белән җанлы элемтәдә булу урнына, физкультура-спорт буенча район уполномоченные иптәш Садыйков язышу белән генә шөгыльләнә. Авылларга — колхозларга чыгып йөрү түгел, аның шәһәрдәге зур коллективларда (педучилище, урта мәктәпләр) һәм җәмгыятьләрдә дә булганы юк.

Райондагы физкультура һәм спорт эшләре белән комсомолның район комитеты бөтенләй шөгыльләнми. ВКП(б) ның Мамадыш райкомы тарафыннан да башлангыч партоешмаларга тиешле күрсәтмәләр бирелгәне юк. Менә шуның нәтиҗәсендә комсомолның күп кенә башлангыч оешмалары яшьләргә физик тәрбия бирү эшендә эшләмиләр. Мәсәлән, спирт заводында эшләүчеләрнең күпчелеге яшьләр. Заводта комсомол членнары гына да 25 кешедән артык. Бу заводта „ГТО“ значкистлары бары тик 15 кеше генә исәпләнә.

МТС һәм МТМ да да, элемтә, райпотребсоюз коллективаларында да физкультура эше гаять начар куелган.

Колхозларда физкультура эшен чын магнәсе белән оештырып җиткерүгә игтибар бирмиләр.

Пионерлар һәм мәктәп балалары арасында физкультураның нинди зур һәм әһәмиятле урын тотуын һәр кем белә. Ләкин Мамадыш районы мәгариф бүлеге дә, комсомолның район комитеты да, бу эшкә гафу ителмәслек рәвештә игтибарсыз карыйлар. ВЛКСМ Үзәк Комитетының X нчы пленумының бу турыда булган карарлары үтәлми. Мәсәлән, 2 нче номерлы урта мәктәптә „ГТО“ буенча масса-өйрәнү эшләре дә алып барылмый, мәктәпнең спорт базаларын булдыру турында да кайгыртучы юк.

Мамадыш районында физкультура һәм спорт өлкәсендә булган мондый һәм моңа ошашлы кимчелекләрне бик күп санарга мөмкин.

Районда физкультура һәм спорт эшләренең бу хәлдә торуына ВКП(б) ның Мамадыш райкомы, комсомол райкомы һәм район мәгариф бүлеге тиешле игтибарны юнәлдерерләр һәм кичекмәстән җитешсезлекләрне бетерү чараларын күрерләр дип уйлыйбыз.

Г. Ногманов.

Чит илләрдә

Германия меморандумына Швеция хөкүмәтенең җавабы

БЕРЛИН, 10 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросы 9 нчы апрельдә иртә белән Германия хөкүмәтенең Швеция хөкүмәтенә меморандум җибәргәнлеген хәбәр итә. Германия хөкүмәте үзенең меморандумында Германиянең Даниядәге һәм Норвегиядәге чараларына карата Швеция хөкүмәтенең нинди позиция алуы турында җавап бирергә такдим иткән. Швециянең чит ил эшләре министре 9 нчы апрельдә кич белән Германиянең Стокгольмдагы илчесенә бу меморандумга җавап тапшырган. Швеция хөкүмәте үзенең җавабында, үзенең электәгечә нейтралитет политикасын дәвам иттерәчәген һәм Германиянең Даниядәге һәм Норвегиядәге чараларына каршы юнәлдерелгән нинди булса да адымнар кулланырга уйламаганлыгын белдергән. Швеция хөкүмәте үзенең җавабында, Германия белән Швеция арасында конфликт китереп чыгару өчен сәбәп булып хезмәт итәрлек чаралар үткәрергә уйламаганлыгын күрсәткән.

НЕЙТРАЛЬ ИЛЛӘР БЕЛӘН ПАРОХОДЛАР ЙӨРЕШЕ, АВИАЦИЯ ЮЛЫ ТУРЫНДА, ТЕЛЕГРАФ ҺӘМ ТЕЛЕФОН ЭЛЕМТӘСЕ ТУРЫНДА АНГЛИЯ ВЛАСТЬЛАРЫНЫҢ БОЕРЫГЫ

ЛОНДОН, 10 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англиянең экономик сугыш министрлеге, Скандинавия илләренә яки Балтык буе дәүләтләренә бара торган барлык пароходлар (кайсы илнеке булуларына карамастан), көтелә торган вакыйгалар уңае белән тиз арада үзләренең хәрәкәтләрен туктатырга тиешләр дип боерык биргән.

Аннары агентлык түбәндәгеләрне хәбәр итә: Англиянең почта министре боерыгы буенча Дания, Эстония, Финляндия, Гренландия, Латвия, Литва, Норвегия һәм Швеция белән почта элемтәсе вакытлыча туктатыла. Бу илләр белән телеграф һәм телефон элемтәсе дә чикләнмәгән вакытка шулай ук туктатылачак.

Голландиянең һава элемтәсе компаниясе (К. Л. М.), Англия властьларыннан алынган боерык нигезендә, Англия белән Голландия арасындагы һава юлларында үзенең эшен вакытлыча туктатканлыгын белдергән. Бу боерык, шулай ук, Англияне нейтраль илләр белән бәйли торган башка авиация юлларына да кагыла.

ДАНИЯ БЕЛӘН ШВЕЦИЯ АРАСЫНДА ЭЛЕМТӘНЕҢ ТУКТАЛУЫ

БЕРЛИН, 10 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Даниянең дәүләт тимер юллар идарәсе Копенһаген белән Мальма арасында, шулай ук Хельсингер белән Хельсингборг арасында, ягни Эресунд бугазы аркылы Даниядән Швециягә бара торган ике тимер юлда да элемтәне туктату, шулай ук Дания аркылы барлык һава трассаларын ябу турында белдергән.

ГЕРМАНИЯ КРЕЙСЕРЛАРЫНЫҢ ТРОНГЕЙМГА КИЛҮЛӘРЕ

НЬЮ-ЙОРК, 10 апрель. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының Лондоннан хәбәр итүенә караганда, Германиянең 4 крейсеры Тронгеймга килгән. Германия гаскәрләре бер нинди каршылыкка очрамыйча Тронгеймны 2 сәгать эчендә алганнар.

Норвегия ярлары янында сугыш

ЛОНДОН, 10 апрель. (ТАСС). Англиянең һава министрлегенең белдерүенә караганда, кичә кич белән Англия самолетлары Германиянең Бергендә тора торган сугыш корабларына берничә тапкыр һөҗүм иткәннәр. Бомбардировка нәтиҗәсендә Германиянең бер крейсеры бик нык зарарланган. Англия самолетлары үз базаларына уңышлы рәвештә кайтканнар.

ЛОНДОН, 10 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгы Германиянең бер эсминецы бик нык зарарланганлыгын хәбәр итә.

ЛОНДОН, 10 апрель. (ТАСС). Англиянең диңгез министрлеге бүген түбәндәге рәсми белдерүне иглан итте: „Бүген таң алдыннан Англиянең эсминецлары Нарвик портында дошманның сугыш корабларына атака ясадылар. Англия эсминецлары көчле каршылыкка очрадылар. Сугыш нәтиҗәсендә Англиянең „Хантер" эсминецы батты, ә „Гарди" эсминецы комга утырды. Башка сугыш кораблары сугышны туктаттылар һәм Норвегия суыннан киттеләр. Үтерелүчеләр һәм яраланучылар турында хәзергә бер нәрсә дә билгеле түгел. Шулай ук дошманның югалтулары турында да дөрес мәгълүматлар юк. Шулай да, Стокгольмнан алынган һәм расланмаган хәбәрләргә караганда, сугыш вакытында Германиянең бер крейсеры батырылган. Безнең бер су асты көймәсе узган төндә Норвегиянең көньяк ярлары янында дошманның крейсерына торпеда атакасы ясаган. Бер торпеда крейсерга эләккән. Бүген Англия бомбардировщиклары Берген янында Германия крейсерына һөҗүм иттеләр. Самолеттан ташланган 3 бомба крейсерга эләккән".

* * *

Рейтер агентлыгына алынган хәбәрләргә караганда, 1.340 тонна авырлыктагы „Хантер" эсминецы диңгез төзелеше программасы буенча 1934 нче елны төзелгән. Эсминецның бәясе—300 мең фунт стерлинг. „Хантер" 12 сантиметр калибрлы 4 орудие белән, кимрәк калибрдагы алты орудие белән һәм сигез торпеда аппаратлары белән коралланган булган. Гади шартларда эсминецның командасы 175 кешедән гыйбарәт булган.

Флотилиянең лидеры 1.455 тонна авырлыктагы „Гарди" 1936 нчы елны эшләнеп беткән. Эсминецның бәясе—343 мең фунт стерлинг. „Гарди" 36 узелга кадәр тизлек белән йөргән. Ул 12 сантиметр калибрдагы биш орудие белән, кимрәк калибрдагы алты орудие белән һәм сигез торпеда аппаратлары белән коралланган булган. Аның да командасы 175 кешедән гыйбарәт булган.

Рузвельтның белдерүе

НЬЮ-ЙОРК, 10 апрель. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, кичә Рузвельт, Гайдпарктан Вашингтонга барышлый, матбугат вәкилләренә, ихтимал 10 нчы апрельдә төнлә белән нейтралитет турындагы законның Норвегиягә карата да кулланылачагы иглан ителер дип белдергән. Рузвельт хәзерге вакытта бу законның шулай ук Даниягә дә кагылырмы икәнлеген дөрес итеп әйтү мөмкин түгел, чөнки Даниядә сугыш хәрәкәтләре турында хәбәрләр юк, дигән.

Аннары Рузвельт, хәбәрчеләрнең Германиянең Скандинавиядәге хәрәкәтләре сугышны АКШ ка якынайтамы, дигән сорауларына җавап биреп, соңгы 48 сәгать эчендә булган вакыйгалар, һич шиксез, күп кенә америкалыларны сугыш ихтималы турында уйларга мәҗбүр итә, дип белдергән. Шулай ук Рузвельт, Вашингтонда булганнан соң ул бик тизлек белән дәүләт секретаре Хэлл һәм Уэллес белән сөйләшәчәген белдергән. Голландия хөкүмәтенең нейтраль илләрнең хөкүмәтләренә нейтралитетны бозуга каршы бердәм протест белдерергә такдим итүе турындагы сорауга кагылып, Рузвельт, бу турыда үзенә бер нәрсә дә билгеле булмавын әйткән.

Вахитов исемендәге клубта Сталин районы мәктәпләрендә укучы балаларның художество үзешчәнлеге олимпиадасын йомгаклауга багышланган кичә булды. Рәсемдә: олимпиадада алдынгылыкны алган һәм бүләкләнгән җыр һәм бию ансамбле. (51 нче номерлы мәктәп). И. Галиев фотосы.

БЕРЕНЧЕ МАЙ АЛДЫ ЯРЫШЫ

ЙӨКЛӘМӘЛӘР ҮТӘЛӘ

Вахитов исемендәге җиркомбинат коллективы республикабызның XX еллыгына һәм Беренче Май бәйрәменә яңа уңышлар белән каршылау өчен көн саен хәзерлек алып бара. Комбинатның завод, цех, смена бригадалары һәм аерым эшчеләр арасында социалистик ярыш договорлары яңартылып төзелә. [illegible] Бу завод март ае планын 127,6 процент итеп үтәде һәм яхшы сыйфатлы продукция җитештерде.

Сабын, стеарин һәм гидрозавод коллективлары да март аенда шактый яхшы эшләделәр. Бу заводлар айлык планы 109—114 процент итеп үтәделәр. Комбинат буенча айлык план 105,2 процент итеп үтәлде.

Комбинатның алдынгы эшчеләреннән Гаврилушкин, Кашапов, Зимин иптәшләр айлык планны 150—180 процент, Ефремов, Сабиров, Агафонов иптәшләр җитәкчелек итә торган бригадалар 130—150 процент итеп үтиделәр. Комбинат коллективы апрель аенда тагын да яхшырак эшләү өчен көрәшә.

Мифтахов.

АЛДЫНГЫЛАРГА ТИГЕЗЛӘНИК

Киез итек-фетр фабрикасы (Казан) стахановчылары 1 нче Май бәйрәмен производствода яңа җиңүләр белән каршылау өчен көрәшәләр. Хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да үстерү өчен яңа йөкләмәләр алалар.

Фабриканың алдынгы эшчеләре, нормаларны яңадан карап чыгу һәм 8,70 процент үстерү кирәклеге турында конкрет такдимнәр бирәләр. Сулау цехы стахановчысы иптәш Фаттахов яңа нормаларны 200 процент итеп үти. Түшәү цехы стахановчыларыннан Габидуллина, Шарипова һ. б. иптәшләр дә яңа норманы арттырып үтиләр һәм яхшы сыйфатлы продукция җитештерәләр.

Ләкин фабрика һәм кайбер цех җитәкчеләре эшчеләрнең производство активлыкларын тагын да күтәрү эшенә тиешле әһәмият биреп җиткермиләр. Социалистик ярыш договорларының үтәлеше тикшерелми. Чистарту һәм отделка цехларында ярыш договорларының үтәлеше январь аеннан бирле тикшерелгәне юк.

Х. Галиев.

Оста башкаручылар кичәсе

Залда тынлык урнашты. Сәхнәдә нечкә авазлардан бердәм рәвештә чыккан көчле җыр яңгырады. Бу, Сталин районы 8 нче номерлы мәктәпнең хоры. Педагоглардан Башмаков һәм Новиков иптәшләр җитәкчелегендә яхшы оешкан балалар хоры „Сталин турында җыр" һәм башка номерларны зур осталык белән башкарды.

Бер-бер артлы алмашынып торган номерлар кичәнең программасын баетканнан-баета барды. 51 нче һәм 12 нче номерлы мәктәпләрнең җыр һәм бию ансамбльләре, 2 нче номерлы мәктәпнең шумовой оркестры (җитәкчесе 8 нче класс укучысы Рафаэлов) һәм башка мәктәпләрнең чыгышлары кичәдә катнашучыларда бик яхшы тәэсир калдырдылар.

Аерым башкаручылардан пионер Әхмәтҗановның (13 нче номерлы мәктәп) гармоннарда уйнавы, укучы Матвееваның (85 нче номерлы мәктәп) зур осталык белән сөйләнгән декламацияләре, IV нче класс укучыларыннан Хәкимова һәм Шаһвәлиеваларның (80 нче номерлы мәктәп) биюләре шулай ук көчле кул чабулар белән каршыландылар.

Укучы балаларның район күләмендәге (Сталин районы мәктәпләре буенча) олимпиадасына йомгак итеп Вахитов исемендәге клубта үткәрелгән бу кичәдә моннан башка да бик күп номерлар башкарылды. Иң яхшы номерларны башкаручылар шәһәр күләмендә үткәреләчәк олимпиадада катнашу хокукын алдылар.

Кичәдә катнашучы оста башкаручылар мәктәп коллективлары, ансамбль, хор, балет җитәкчеләре бүләкләнделәр.

Р. Н.

ЛЕНИННЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ ТУЛУ КӨНЕНӘ ХӘЗЕРЛЕК

Казан Кызыл Армия йорты революция даһие В. И. Лениннең тууына 70 ел тулу көненә Ильич әсәрләреннән китап күргәзмәсе хәзерли. Күргәзмә өчен кирәкле материаллар туплана. Күргәзмә 17 нче апрельдә ачылачак. [illegible]

Маяковскийга багышланган күргәзмә

Татарстан АССР ның В. И. Ленин исемендәге фәнни китапханәсендә Владимир Маяковскийга багышланган күргәзмә төзелә. Күргәзмә 5 бүлектән тора. [illegible]

14 нче апрельдә, Маяковскийның үлүенә 10 ел тулу көнендә, [illegible]

КАЗАН МУЗЕЕНЕҢ 45 ЕЛЛЫГЫ

Шушы елның апрель аенда Казан музеенең ачылуына 45 ел тула. [illegible]

Казан музее тарих-этнография җәмгыяте тарафыннан 1895 нче елда шәһәр музее булып ачыла. [illegible] 1938 нче елда музейга 65 мең кеше, 1939 нчы елда 130 меңнән артык кеше булды.

Юбилейгә музейнең яңа разделлары ачылачак.

Математика олимпиадасы

Казан Дәүләт Университеты янындагы Фәнни-Тикшеренү Математика һәм Механика институты шәһәр мәктәпләрендә укучылар һәм математика белән кызыксынучылар өчен математика олимпиадасы үткәрә.

[illegible]

ЯЗГЫ АУ

Татарстан Халык Комиссарлары Советы карары буенча, [illegible]

К. Софонов.

Төркмәнстанда яңа алфавит

АШХАБАД, 4 апрель. (ТАСС). Бүген республика газеталары төркмән теленең яңа алфавиты проэктын басып чыгардылар. Проэктны Төркмәнстан тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институты төзегән. Рус графикасы нигезендә төзелгән бу алфавитта 37 хәреф һәм бер апостроф бар. Апрель аенда алфавит проэкты һәм орфография кагыйдәләре киңәшмәләрдә тикшереләчәк, аннары Төркмәнстан Верховный Советы Президиумы раславына кертеләчәк.

Старшина Шевченко

Кече лейтенант иптәш Кувшинов командованиесендәге подразделениенең курсантлары старшина Шевченконы яраталар һәм олылыйлар.

Подразделениегә иптәш Шевченко күптән түгел генә килде. Шулай да ул үзен танытырга өлгерде. Курсантлар аны яхшы иптәш булуы, аталарча кайгыртучанлык күрсәтүе өчен яраталар.

Курсант иптәш Вязнин аның турында менә нәрсә ди:

— Мин күптән түгел дневальный булып тордым. Төнлә курсантлар тыныч йокыда иделәр. Ләкин старшина уяу иде әле. Ул торып бүлмәләрне карап, күзәтеп чыкты. Аннан соң өсләре ачылган курсантларның өсләренә одеялларын япты, соңыннан, аңа барсы да тәртиптә күренгәч кенә, тынычлап йокыга китте.

Иптәш Шевченко Кызыл Армия сафында 7 ел тоташтан хезмәт итә. Ул срогын тутыргач та үзе теләп Кызыл Армиядә хезмәт итәргә калган. Укырга теләге барлыгын белдергәч, аны хәрби пехота училищесенә укырга җибәргәннәр.

Иптәш Шевченко күп тапкырлар мактау алган һәм бүләкләнгән алдынгы старшина. Ул 62 тапкыр рәхмәт, 5 тапкыр кыйммәтле бүләк алган.

Старшина иптәш Шевченко училищене отлично билгесенә генә бетерергә уйлый.

М. Сафин.

СОВЕТ РАДИОТАПШЫРУЫНЫҢ XV ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАНГАН КИЧӘ

7 нче апрельдә Зеленодольскиның Париж Коммунасы исемендәге клубында совет радиотапшыруының XV еллыгына багышланган тантаналы җыелыш булды.

Җыелышта Совет радиосының XV еллыгы турында доклад белән Татарстан Радиокомитеты председателе иптәш Батталов чыкты.

[illegible]

И. Файзуллин.

Күп балалы аналарга пособие

Быел күп балалы аналарга пособие түләүгә 1.162 миллион сум акча бирү билгеләнә. [illegible] 1.104 [illegible]

[illegible] (ТАСС).

ЕЛГАЛАРДА

Волга суы 11 нче апрельгә каршы бер тәүлек эчендә Горький янында 37 сантиметр, Кама Тамагы янында 44 сантиметр, Тәтеш янында 30 сантиметр, Куйбышев янында 58 сантиметр артты. Түбән Услан янында тыгылган боз ага башлау сәбәпле Казан янында 26 сантиметр су кимеде. Кама Тамагы, Сенгилей һәм Куйбышев янында көчле рәвештә боз ага. Козмодемьянский һәм Камышин янында боз кузгалды.

Кама суы Сарапул янында 17 сантиметр, Красный Бор янында 72 сантиметр, Чистай янында 53 сантиметр, Лаеш янында 3[illegible] сантиметр артты. Красный Бор һәм Сокол[illegible]ка янында боз кузгалды.

Агыйделдә сирәк-сирәк боз агып тора.

Вятка суы Вятские Поляны янында 55 сантиметр, Мамадыш янында 30 сантиметр артты. Мамадыш янында боз кузгалды.

БЕЛДЕРҮ

Элек Ютазы районында эшләгән **Константин Андреевич Нестров** һәм элек Партиянең Апас районы оешмасында учетта торган **Хәйреттин Хөснеттинов** иптәшләрнең ВКП(б) Өлкә Комитетының оештыру-инструкторлык бүлегенә килүләре сорала.

Югарыда фамилияләре күрсәтелгән иптәшләрнең тору яисә эшләү урыннарын белүчеләрдән,—ул турыда ВКП(б) Өлкә Комитетына белдерүләре сорала.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
13 нче апрельдә Зур Драма театры бинасында
ФАУСТ
15 нче апрельдә Татар Дәүләт Академия театры бинасында, Татарстан АССР ның атказанган артисткасы
МӘРЬЯМ РАХМАНКУЛОВА
КОНЦЕРТЫ
Кич 8 сәгаттә башлана.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 12 нче апрельдә көндез 12 сәгаттә
КУРКЫНЫЧЛЫ СУД
һәм кич
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
12 нче апрельдә көндез һәм кич
ШӘМСЕКАМӘР
14 нче апрельдә
КЫЮ КЫЗЛАР
Талоннар белән кертелми.
Спектакль кич 8 сәгаттә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн 3 бүлектә
ЗУР ЦИРК УЕНЫ
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
ЯРЫШЫ
ҺӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ
Бүген, 12 нче апрельдә
ЗУР ПРОГРАММАДА
КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ
Уеннар көндез 12 дә, кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы яңа фильм АРИНКА
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	ШАТЛЫК ЭЗЛӘГӘНДӘ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8, 10 да.	ШӘХСИ ЭШ
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6-30, 8 һәм 10 да.	КАБАРДА АТЛЫСЫ Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник" 6, 8 һәм 10 да.	ТАШЛАНДЫК
„РОТ-ФРОНТ" 6, 8, 10 да.	КАТЕРИНА
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	ГРОЗА

ГЕРМАНИЯ АРМИЯСЕ ВЕРХОВНЫЙ КОМАНДОВАНИЕСЕНЕҢ СВОДКАСЫ

БЕРЛИН, 10 апрель. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе түбәндәге сводканы иглан итте: „Көнбатыш фронтта әһәмиятле бер нинди дә вакыйгалар булмады.

Даниядә һәм Норвегиядә хәрби чаралар кичә генерал фон Фалькенхорстның баш командованиесендәге армия, флот һәм авиация частьләренең нык рәвештә үзара ярдәмләшеп хәрәкәт итүләре белән үткәрелде. Хәрби диңгез көчләренә генерал-адмирал Заальвехтер һәм адмирал Карльс җитәкчелек итте. Күп санлы һава берләшмәләренә генерал-лейтенант Зейслер җитәкчелек итте. Генерал Каупиш җитәкчелегендәге моторлаштырылган—бронемеханик частьләр иртә белән Германия—Дания чиген үтеп чыктылар, Апенарде һәм Эсбьерг аркылы бик тизлек белән алга баруны дәвам иттереп, Ютландияне алдылар. Бу алга бару вакытында Дания гаскәрләре белән аерым бәрлешләр булды. Дания гаскәрләре бер нинди каршылык күрсәтмәскә дип үз хөкүмәтләреннән приказ алганнан соң бу бәрлешләр туктатылды. Ютландияне алу белән бер үк вакытта, хәрби диңгез флоты һәм авиация ярдәме белән, Германия гаскәрләре атауларны алу өчен Фюн атавындагы Миддельфарт якынындагы Кечкенә Бельт бугазына, Корсер һәм Нюборг якынындагы Зур Бельтка, шулай ук Гедсерга төшерделәр. Копенгаген иртә белән үк инде сугышсыз алынган иде. Германия авиациясе Дания территориясе өстендә көн буена күзәтү очышлары үткәрде, шулай итеп Германия гаскәрләренең алга баруларын тәэмин итте.

Норвегиянең әһәмиятле стратегик терәк пунктларын алган вакытта төрле участкыларда немецләргә каршылык күрсәтелде. Германиянең коралл көчләре көн буена Осло-Фиордтагы фортларны алдылар. Нарвик, Тронгейм, Берген, Ставангер, Эгерсунд, Кристиансунд, Арендаль һәм Осло немецләр кулында. Шулай итеп Германиянең хәрби диңгез флоты үзеннән бик күп тапкырлар өстен булган Англия—Франция флотына каршы юнәлдерелгән операцияне тәэмин итү һәм транспортларның походын һәм десант төшерүне җиңеләйтү буенча үз алдына куелган бурычны үтәде. Ослодан алып Нарвикка кадәр булган барлык пунктларга да диярлек Германия гаскәрләрен төшерү мөмкин булды. Портларга кергән вакытта Германия хәрби флотына каршылык күрсәтүне бастырырга туры килде. Германиянең диңгез артиллериясе Норвегиянең Осло янына урнаштырылган авыр яр буе батареяләрен атудан туктарга мәҗбүр итте. Сугыш вакытында Норвегиянең 28 сантиметрлы орудиеләрдән тора торган бер батареясе тарафыннан Германиянең „Блюхер" крейсеры каты зарарланды. Алга баруын дәвам иттергәндә, крейсер Норвегия миналарына эләкте һәм батты. „Карлсруэ" крейсеры десант төшергәннән соң Кристиансунд янындагы сугышта бик нык зарарланды һәм батты. 2 карабтагы командаларының күпчелек өлеше коткарылды һәм ярга алып чыгылды. Диңгездә операцияләр дәвам итә.

Норвегия суларына миналар кую белән үк Англия Норвегиянең әһәмиятле терәк пунктларын алырга тиеш булган. Германиянең хәрәкәтләре англичаннарның бу омтылышына юл куймады. Англиянең шушы теләк өчен билгеләнгән хәрби диңгез көчләре һәм гаскәр транспортлары кичә кич белән Германиянең һава разведкасы тарафыннан ачылдылар һәм атакага алындылар. Дошманның барлык диярлек сугыш кораблары да авыр бомбалардан зарарландылар. 4 линкор, 2 линейный крейсер, 2 авыр крейсер зарарланды. Бер авыр крейсер янды. Шулай ук 2 транспорт зарарланды.

Даниянең һәм Норвегиянең көнбатыш ярларында шулай ук Германиянең эчке бухтасында Германиянең истребительләр эскадрельеләренең патрульлек итүләре операцияләр үткәрүне тәэмин итте. Англиянең „Сандерлэнд" типындагы оча торган бер көймәсе бәреп төшерелде. Норвегиянең башка территориясен алу тиз һәм планлы рәвештә дәвам итә".

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1379. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1385.